Муниципальное казённое учреждение
“Управление образования исполнительного комитета
Азнакаевского муниципального района”
Республики Татарстан

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
“Гимназия города Азнакаево”
Азнакаевского муниципального района Республики Татарстан

# Опыт, проблемы, перспективы преподования родного (татарского) и английского языков в школе

*Региональный семинар учителей начальных классов,
учителей английского и татарского языков*

*(18 марта 2021 года)*

*Материалы*

***Азнакаево, 2021***

*Печатается по решению Методического Совета*

*МБОУ “Гимназия г. Азнакаево” от 06.04.2021г.*

*Составители:*

*Рахманов А.М., директор МБОУ “Гимназия г. Азнакаево” Азнакаевского муниципального района;*

*Хусаинова Ф.В., заместитель директора по учебной работе МБОУ “Гимназия г. Азнакаево” Азнакаевского муниципального района;*

*Ибрагимова Ч.Р., заместитель директора по инновационной работе МБОУ “Гимназия г. Азнакаево” Азнакаевского муниципального района;*

*Мирсияпова Г.Г., руководитель ШМО филологических наук МБОУ “Гимназия г. Азнакаево” Азнакаевского муниципального района;*

*Рахманова Ф.И., руководитель ШМО учителей начальных классов МБОУ “Гимназия г. Азнакаево” Азнакаевского муниципального района;*

*«Опыт, проблемы, перспективы преподавания родного (татарского) и английского языков в школе», региональный семинар (18 марта 2021 года). Материалы регионального семинара. – Азнакаево, 2021 – 89 с.*

*Рахманов Альберт Магалимович,*
*Азнакай муниципаль районы*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе” директоры*

**Гимназия шартларында укучыларда милли үзаң тәрбияләү**

Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру – хәзерге буынның төп вазифасы. Күңелендә аз гына милли хисе булган кеше моңа битараф кала алмый торгандыр.

Хәзерге чорда радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, рухына әдәпсезлек үрнәкләрен сеңдергән заманда, милләтнең гасырлар буе формалашкан тәҗрибәсе, әхлак кагыйдәләре югала бара. Менә шуның өчен дә мәктәп, гимназияләрдә укучыларга халкыбыз хәзинәләре нигезендә милли үзаң тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелергә тиеш.

Халыкның бүгенгесе, киләчәге, дөньякүләм тоткан урыны, һичшиксез, аның аң-белем дәрәҗәсенә, рухи-әхлакый үсешенә турыдан-туры бәйле.

Азнакай шәһәре гимназиясе алдында торган иң әһәмиятле бурычлар да туган телебезне, тарихыбызны өйрәнү, яшь буында милли үзаң формалаштыру, иҗади, көндәшлеккә сәләтле, толерантлы, сыйфатлы белем алган заманча шәхесләр тәрбияләү. Бүгенге көндә төрле телләрне өйрәнүдә, шәхес тәрбияләүдә гимназия зур урын алып тора. Татар теле белән бер рәттән, гимназиядә инглиз, рус телен тирәнтен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Төрле телләрдә иркен аралаша торган укучылар тәрбияләү, бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырырга да ярдәм итә. Безнең күрсәткечләребезнең республика, район күрсәткечләреннән югары булуы шуны раслый.

Азнакай шәһәре гимназиясендә укучыларга милли тәрбия бирү берничә юнәлештә алып барыла. Бу юнәлешләргә түбәндәгеләр керә:

1. Тел өйрәтү.
2. Халыкның әдәбиятын, әдәбият аша мәдәниятен өйрәтү, гореф-гадәт, тарихына карата кызыксыну уяту.
3. Кызыксыну уятып кына калмыйча, класстан тыш чаралар ярдәмендә шул мохит, шул тирәлектә яшәү ихтыяҗы тудыру.
4. Хәзерге чор балаларын милли үзаңлы итү өчен, аларның ата-аналары белән һәм гаилә аша эш итү.

Әлеге эшләрне бер дәрәҗәдә алып бару һәм туктаусыз үстерү генә яхшы күрсәткечләргә, нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Гимназиядә татар телен саклау, милли тәрбия бирү белән һәр мөгаллим шөгыльләнә. Барлык укытучыларыбыз татар телендә камил сөйләшәләр. Тел дәресләрендә укучыларга туган телне, әдәбиятны тирәнтен өйрәтүгә, халкыбызның бай рухи мирасын пропогандалауга, балаларда милли үзаң, горурлык хисләре тәрбияләүгә, татар дөньясының иҗтимагый, сәяси, мәдәни тормышы белән якыннан һәм даими таныштырып баруга әһәмият бирәбез.

Бу укучыларыбызның республика күләмендә уздырылган бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә, олимпиадаларда уңышлы чыгыш ясаулары белән билгеләнә.

Балаларда  милли үзаң үстерүдә дәрестән тыш үткәрелә торган чаралар да зур әһәмияткә ия. Укучылар һәм укытучылар район күләмендә, гимназиядә үткәрелгән бу чараларда актив катнашалар. Традицион милли бәйрәмнәр белән бер рәтттән, гимназиянең үз традицияләренә әйләнгәннәре дә еш уздырыла. Боларга “Гимназистлар балы”, “Туган тел”, гаилә бәйрәмнәре, әдәби кунакханәләр керә.  Алар барысы да халкыбызның күңел бизәкләрен  киләчәк буынга җиткерүгә,

балаларда милли үзаң тәрбияләүгә юнәлтелгән. Гимназиядә 100% татар балалары укуын исәпкә алсак, бу кирәкле һәм әһәмиятле эш.

Балаларның иҗади мөмкинлеген үстерү максатыннан, гимназиябездә “Яшь редактор”, “Сәхнә”, “Фольклор”, “Радиоүзәк” студияләре эшләп килә.

Гимназиянең тышкы элемтәләр булдыру, социаль партнерлыкны җәелдерү өстендә алып барылган эшчәнлеге дә, укучыларда милли үзаң тәрбияләүгә уңай йогынты ясый. Азнакай районы “Ак калфак” хатын-кызлар җәмгыяте оешмасы белән тыгыз элемтәдә булу да очраклы хәл түгел. Беренчедән, гимназиянең татар теле укытучылары үзләре дә бу оешма әгъзалары, икенчедән, аларны бер үк максат берләштерә, ул татар халкының милли гореф-гадәтләрен саклау һәм шул гореф-гадәтләрнең кануны нигезендә балаларны тәрбияләүдән гыйбарәт. Гимназия кысаларында укучыларда милли рух һәм патриотик тәрбияне ныгытуга юнәлдерелгән чаралар, татарча көрәш түгәрәгенең эшләп килүе, татар орнаментлары белән чигү, гимназиядә гадәттәге звонок чыңының татар халык көйләренә алыштырылуы бу хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе булып тора.

Инновацион белем бирү учреждениясе буларак гимназия һәрвакыт республика, район җитәкчелеге тарафыннан игътибар үзәгендә. Гимназиягә куелган таләпләр дә югары.

Яшь буынның бүген алган тәрбиясе – халкыбызның алдагы көне ул. Милли мәгарифне, татар телен саклау һәм үстерү буенча гимназиядә зур эш алып барыла.

*Шәмсиева Гөлназ Миннегәрәевна,*
*“Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе” методисты*

## Азнакай муниципаль районында милли мәгариф

Бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып торган милли мәгариф системасын без киләчәк буынны гаилә, балалар бакчасыннан алып, югары мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту буларак күз алдында тотабыз. Азнакай муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү программасын тормышка ашыру буенча милли белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар һәм мөмкинлекләр тудырылган. Азнакай муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә татар теле һәм әдәбиятын укыту Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм дәүләт программалары аша гамәлгә ашырыла, 23 мәгариф учреждениесында 10 нан артык милләт вәкиле булган 6829 укучы белем ала, шул исәптән татар милләтеннән 5589 (81,8%), рус милләтеннән – 699 (10,2%), башка милләтләрдән 541 (8%).

Татар телендә 1156 укучы белем ала, бу 20,6%, районда татар телендә тәрбия бирү 27,1 % тәшкил итә.Рус телендә 5673 укучы белем ала, бу - 79,4%. Районда татар телендә белем бирүче 11 мәктәп эшли, шул исәптән 1 гимназия, 9 урта мәктәп, 1 төп мәктәп. Шулай ук 6 филиалда укыту һәм тәрбия татар телендә.

“Татар теле” предметын өйрәнү барлык 23 гомуми белем бирү учреждениесендә дә алып барыла. Татар телен туган тел буларак 95% укучы, рус телен 5% укучы сайлады.

Халыкның 80 % тан артыгы милләте буенча татарлар булган район өчен иң мөһиме - татар телендә белем һәм тәрбия бирүне арттыру бурычы.

Мәгариф учреждениеләре коллективлары алдына татар милләтендәге барлык балаларны туган (татар) телендә тәрбияләүне колачлау бурычы куелды.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының гомуми саны тотрыклы булып кала һәм бүгенге көндә мәктәпләрдә 172 укытучы эшли, шуларның 71е татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 101 башлангыч сыйныф укытучысы, 22 укытучы югары категорияле. Барлык педагоглар да югары һөнәри белемгә ия.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының югары профессиональлеге ирешелгән нәтиҗәләр белән раслана:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туган татар телендә белем бирүче педагог хезмәткәрләргә ярдәм» грант конкурсында 3 татар теле һәм әдәбияты укытучысы җиңүгә иреште. (**Кашапова Ф.Ф, Шакирова Г.М-7 нче мәктәп, Ихсанова Э.Т.-Урманай).**

Азнакайның 7 нче урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Шакирова Гөлназ Малик кызы** Бөтенроссия туган тел укытучыларының “Туган тел” мастер-класс бәйгесендә Гран-при яулады.

Актүбә бистәсе 2 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Шагалиева Гөлназ Нәҗип кызы**, “Татар теленең виртуаль кабинеты” республика конкурсында җиңде.

Урманай урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Ихсанова Эльвира Таһир кызы**, 2021 нче елның Парламент дәресе кысаларында “Татарстан - безнең уртак йортыбыз. Халыклар бердәмлеге, мәдәни һәм тел күптөрлелеге республиканың уникаль байлыгы" конкурсында җиңүче.

Мәгариф оешмаларында туган (татар) телен өйрәнүнең нәтиҗәсе булып олимпиада һәм бәйгеләр хәрәкәте нәтиҗәләре тора.

Урманай мәктәбенең 10 сыйныф укучысы **Камаев Илнар** татар теленнән VIII Халыкара олимпиадада җиңүче булды. Азнакайның 5 нче урта мәктәбе укучысы **Джавадова Айсун** (милләте буенча азәрбайҗан), Азнакайның 4 нче лицееннан **Рахманова Назилә** татар теленнән VIII Халыкара олимпиада призерлары булдылар.

Азнакай шәһәре Гимназиясенең 6 сыйныф укучысы **Латыйпов Нариман** «Җәлил укулары» Халыкара әдәби конкурсының республика этабында җиңүгә иреште.

Туган телләр елы кысасында укучыларыбыз халыкара, республикакүләм бәйге, фәнни-гамәли конференцияләрдә **32** призлы урынга ия булдылар.

18 гомуми белем бирү учреждениесендә туган як тарихын, татар халкының мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү буенча өстәмә белем бирү түгәрәкләре эшли. (10 шәһәр, 8 авыл җирлеге). Өстәмә белем бирү 33 берләшмәдә түбәндәге юнәлешләр буенча алып барыла:

-Сәнгать-13 берләшмә(191 укучы);

-Социаль-педагогик -17 берләшмә (234 укучы);

-Туристлык-туган якны өйрәнү-3 берләшмә (42 укучы).

Туган як тарихын, татар халкының мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү буенча 467 бала өстәмә белем ала, бу өстәмә белем бирү түгәрәкләренә йөрүчеләрнең 14% ын тәшкил итә.

1 сентябрьдән Азнакай шәһәренең гимназиясе базасында әрмән халкының туган телен, мәдәниятен, тарихын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү буенча түгәрәк эшли башлаячак.

21 нче гыйнварда Азнакай районының 23 мәктәбе, 56 балалар бакчасында “Туган телләр елы”н ачуга старт бирелде. Безнең төп максатыбыз туган телләргә мәхәббәт, телләрне тирәнтен өйрәнүгә кызыксыну уяту, күренекле кешеләребезне, традицияләребезне барлау, матур сөйләм телендә аралашу, тәҗрибә уртаклашу, халыклар

дуслыгын ныгыту өстендә эшләү. Шул максаттан, Азнакай районының Сарлы, Тымытык, Урсай авылы мәктәпләре, Башкортстан Республикасы Бакалы районының Куштиряк, Урманай, Яңа Урсай мәктәпләре, балалар бакчалары белән берлектә семинарлар, мастер-класслар, фәнни-гамәли конференцияләр, “Түгәрәк өстәл”, шигырь укучылар бәйгеләре үткәрделәр.

Туган телләр елы кысаларында районның “Маяк” газетасы редакциясе каршында “Яшь журналист” мәктәбе эшен башлап җибәрдек.

62 еллык тарихы булган “Гөлстан” әдәби берләшмәсенә 300дән артык яшь каләм тибрәтүчеләр йөри, аларның иҗат җимешләре вакытлы матбугат битләрендә бастырыла, җирле радио, телевидение дулкыннарында яңгырый. Әдәби сөйләм теленә, иҗат серләренә өйрәтү максатыннан якташ шагыйрьләр, язучылар тарафыннан мастер-класслар, очрашулар, бәйгеләр үткәрелә.

“Туган төбәкне өйрәнү музее”, “Халыклар дуслыгы йорты”, “Ак калфак” иҗтимагый оешмасы, Хатын-кызлар, Ветераннар Советы, Иҗтимагый Совет белән берлектә “Татар кызы, татар егете”, “Тәмле казан”, “Хорлар ярышы” бәйгеләре, Халыкара туган телләр көне, күренекле шәхесләребезнең юбилейлары, якташ язучыларыбыз белән очрашулар, яңа китап презентацияләре, туган телләр, халыкларның милли мәдәниятләре фестивале югары дәрәҗәдә үткәрелде. Чараларны тормышка ашыру укучыларда туган телен, мәдәниятен, тарихын өйрәнүгә, татар телендә уку теләге булдыруга, милли мәгариф эчтәлегенең яңаруын, ресурс, методик, информацион яктан якланауына, милли мәгарифнең үсешен объектив һәм үтә күренмәле мониторинглаштыру системасында уңай динамика булдырылуына юнәлтелгән.

*Әхмәдишина Лилия Ильнуровна,*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе” нең башлангыч сыйныф укытучысы*

## Туган телне укытуда заманча һәм инновацион технологияләр

Заман таләпләре бүгенге көндә туган телен укыту процессында зур үзгәреш сорый.  Укытучылар алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны устерү бурычы. Бу укытычыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын һәм иҗади эшли белүне таләп итә.

Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга гына түгел, ә яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлесен сайлап алып, үзләштереп эшли белергә дә тиеш. Заманча технологияләр файдаланып белем бирү түбәндәге мөһим бурычларны үтәргә ярдәм итә:

- укучыда телгә кызыксыну уята;
- аның танып белү активлыгын үстерә;
- укучыларның иҗади мөмкинлекләрен камилләштерә;
- белемнәрне тирәнәйтә.

Информацион технология – компьютер техникасы һәм программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны укучыларга әзерләү һәм җиткерү процессы.

Мәгълүмәти технологияләрне укыту-тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Заманча технологияләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтеп була:

1) шәхескә юнәлтелгән технологияләр;

а) Ш.А. Амонашвилиның шәхескә хөрмәт белән карау технологиясе;

б) үзара хезмәттәшлек педагогикасы технологиясе.

2) укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр;

а) уен технологиясе;

б) проблемалы укыту;

в) аралашуга өйрәтү технологиясе.

3)уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр.

а) терәк схемаларны кулланып, алга китеп укыту технологиясе;

б) белем бирүнең компьютер технологияләре;

в) интенсив белем бирү технологиясе.

Туган тел дәресләрендә информацион технологияләр укытучыга нинди методик мөмкинлекләр бирә?

1) Дәрес материалын күз алдына китерү.

Туган телне укыту процесында информацион технологияләр куллану махсус программаны күз алдында тота.

- Электрон дәреслекләр. Татар теленнән электрон дәреслекләребез бар.
- Контроль ясаучы тестлар. Мондый тестларны дәрес материалына яраклаштырып укытучы да төзи ала.
- Информацион – беләшмә программалар (сүзлекләр, энциклопедияләр).
- Әзер дискларда сүзлекләр очратканым булмады. Без еш кына кирәк булганда сүзлекләрне интернет челтәре аша табып алабыз.
- Күргәзмә программалар (слайд һәм видео-фильмнар). Презентация формасында эшләнгән слайдларны дәресләребездә еш кулланабыз.

“Укытучының тере сүзен бернинди компьютер да алыштыра алмый” дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу сүзләр белән килешәм. Туган тел дәресләрен укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый. Чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барырга тиеш.

Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикри тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли.

Бүгенге укучыларның гыйлем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Безнең кулларда балалар язмышы. Безнең укучыларыбыз, Р.Фәхреддин теләгәнчә, бөтен яктан да үрнәк балалар булып уссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

*Әхмәтҗанова Зөлфия Юратовна*
*Лениногорск шәһәре 8 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Туган тел дәресләрендә укыту материалын визуальләштерү алымнарын куллану

**Максат:** татар теле дәресләрендә заман таләпләренә туры килгән, инновацион алымнар, ысуллар белән таныштыру, әлеге алымнарны практик кулланырга өйрәтү, хезмәттәшләрнең һөнәри үсешенә, педагогик осталыгына йогынты ясарлык эш тәҗрибәсе белән уртаклашу

**Җиһазлау.** Компьютер, проектор, презентация.

**Алымнар:** “Сүзләр болыты”, QR-код, Инфографика онлайн сервислары ярдәмендә төзелгән биремнәр.

**Үткәрү формасы:** Мастер-класс.

Сер түгел хәзерге заман балаларына дәреслекләр укырга, күнегүләр эшләргә, кагыйдәләр ятларга ошамый. Аларның дәресләрдә тик кенә тыңлап утырасылары, ташкын кебек агылган мәгълүматны хәтерләрендә калдырасылары килми. Димәк, балаларны кызыксындыру һәм укыту нәтиҗәле булсын өчен, яңа технологияләр, ысуллар, чаралар, алымнар куллану мөһим.

Дәресләрне ничек итеп мөмкин кадәр заманча, кызыклы һәм сыйфатлы үткәреп була? Үземнең мастер классымда онлайн инструментлар ярдәмендә төзелгән биремнәр, алымнар тәкъдим итәм. Андый ресурслар дәресне интерактив формада үткәрергә мөмкинлек бирә.

Игътибарыгызга *“Сүзләр болыты”* дип аталган текстны визуальләштерүнең бер ысулын тәкъдим итәм. Аны шулай ук укытуда уңышлы кулланырга була. “Сүзләр болытын” төзүне Tagxedo http://www.tagxedo.com, Tagul http://tagul.com, Word It Out http://worditout.com, WordCloud http://wordcloud.pagemon.net, ImageChef http://www.imagechef.com/ic/word_mosaic кебек сервислар тәкъдим итә.

*QR-код.* Бүгенге көндә төрле товарларда мондый кодларны очрату гадәти хәлгә әверелде. Ә укытуда аны ничек итеп кулланып була соң? Мәгълүматны кодлаштырып, аларны дәреснең төрле этапларында кулланырга була. Биремнәрне болай итеп тәкъдим иткәндә, әлбәттә, укучының, бер яктан, фәнгә карата кызыксынучанлыгы артса, икенче яктан мобиль телефонны уку чарасы буларак куллану. Кыска булган текстларны https://decodeit.ru/ он-лайн генераторында бик тиз һәм

җиңел генә кодлаштырырга мөмкин. Укучы смартфон ярдәмендә кодлаштырылган рәсемнең сканын ясап, биремне үти ала.

*Инфографика* – мәгълүматны график рәвештә визуаль күрсәтү. Аның максаты укучыга катлаулы материалны тиз һәм гадиләштереп бирү. Исеме үк әйтеп тора, инфо + графика, ягъни, мәгълүмат + графика. Татарча инфографика материалларын "Гыйлем" интернет сайтында **http://giylem.tatar/** табарга, яки **Piktochart.com**, **Canva.com** кебек төрле интернет-сервислар ярдәмендә үзең төзергә дә була. 90% мәгълүматны баш миенең визуаль формада кабул итүен исәпкә алсак, инфографика, һичшиксез, эффектив ысул булып санала. Сезнең игътибарыгызга "К.Тинчурин турында 5 факт" дигән инфографика тәкъдим итәм.

— Хөрмәтле хезмәттәшләр, мастер-классыбыз ахырына да якынлашты. Әлеге чыгышта китерелгән онлайн ресурсларны куллану буенча гамәли үрнәкләр яшь белгечләргә дә, тәҗрибәле укытучыларга да дәресләрен эффектив, заманча үткәрергә ярдәм итәр.

Үз чыгышымны Мәскәү шәһәренең 1679 нчы санлы "Сәламәтлек мәктәбе" директоры, педагогия фәннәре докторы В.Н.Просвиркин сүзләре белән тәмамлыйсым килә "Бүген заман белән бергә атлау – артта калу дигәнне аңлата. Аны узып китәргә кирәк. Үзеңне киләчәктә күрү кирәк. Әгәр күрсәгез, аны төзегез!"

*Ахметханова Сабина Фанисовна,*
*учитель английского языка*
*МБОУ «СОШ №7 г. Азнакаево»*
*Азнакаевского муниципального района*

## Как научиться запоминать 100 иностранных слов за 1 час?

На запоминание слов английского языка уходят 80% времени, а на грамматику -всего лишь 20% времени и чтобы говорить на языке, нужно иметь хороший словарный запас. Так, как же быть? С одной

стороны, нам нужно знать, как минимум 1000 слов, чтобы говорить на бытовом уровне, с другой стороны, кратковременная память имеет свои границы, то есть 5-7 слов усваивается за одно занятие.

Технология English-память.

Традиционный подход в обучении английскому языку.

Вспомним, как английские слова запоминали мы в школе. Писали английское слово, во второй колонке писали транскрипцию и в третьей шёл перевод. Что происходило? Сначала нам нужно было увидеть английское слово в написанном виде, затем вспомнить произношение этого слова, далее посмотреть на написанное английское слово и вспомним его перевод.

Таким образом, формировался процесс чтения и письма, поэтому стоит ли удивляться что большинство из тех, кто учил язык в школе умеют читать и переводить со словарем, но, к сожалению, не умеют говорить. А почему? Потому что процесс разговорной речи начинается именно с перевода, то есть в обратную сторону давайте сейчас стрелочкой изобразим этот процесс.

В нашей школе открыты билингвиальные классы, в связи с чем обучение многих предметов идет на английском и татарском языке. Стал вопрос: как на уроке изобразительного искусства научить английскому языку (Далее ИЗО)? Благодаря технологии, которую я хочу вам презентовать это вопрос был исчерпан. На уроке ИЗО мы не ограничиваемся пятью словами как требует этого предмет Английского языка (Далее АЯ). Так же я не ограничиваю ребят только цветами на АЯ. Во 2м классе ребенок должен пополнять, обогащать свой словарный запас не только на уровне письма, но и на уровне разговорной речи.

Чтобы легче запоминать английские слова, нужно использовать ассоциации, например, шуба-shugar, путем рисунков, которые мы раскрашиваем, произнося эти слова.

И вот это естественный процесс запоминания слов с помощью рисунков.

Картинка является языком долговременной памяти, зубрешка-кратковременной.

К переводу (значение слова) - пририсован еще один образ-начало слова (созвучное слово).

Видите картинку- работает зрительная память,

Вы ее разукрашиваете-работает тактильная память и одновременно в слух произносите, неоднократно повторяя его.

Таким образом, данная технология действительно работает. Ее стоит использовать на уроках, ведь есть результат.

*Бахтиева Светлана Актасовна,*
*учитель английского языка,*
*МБОУ «Гимназия г. Азнакаево»*

## **Фрагмент урока “Театр сәнгате”, “Theatre (7кл.)**

Как известно, каждый ученик видит мир сквозь призму своей культуры и языка. При обучении английскому языку детей татар в нашей гимназии использование сравнительного изучения дает эффективный результат. Для многих учащихся нашей гимназии легче дается понимание английского языка через родной. Ярким примером тому является сравнение видовременных форм глагола, фонетических, грамматических и лексических разделов языка. Процесс обучения иноязычной речи неразрывно связан с проблемой взаимодействия двух языковых систем в сознании говорящего, поэтому все мыслительные процессы учащихся и психическая деятельность тесно связаны с родным языком.

Разработка фрагмента интегрированного урока «Theatre” («Театр») для с учащихся 7 класса. Цель и задачи урока: обобщение по теме

«Искусство. Театр», систематизация знаний учащихся, развитие лексических навыков говорения и аудирования, эстетическое развитие учащихся, любовь к искусству и воспитание чувства прекрасного.

Ход урока

- Hello, guys! I am really happy to see you here. (Good morning teacher!)

- Исәнмесез балалар! (Исәнмесез!)

- Sit down please. I hope you are all ready for the lesson.

- How are you today? (Everything is cool. Pretty good. Middling…)

- Балалар без бер-беребез белэн исэнлэштек, э исәнләшу ул кешегэ сәламәтлек телэү, кешенең хәлен сораша белү, әдәплелек билгесе. Мин сезне күрүемә бик шат!

- So today we have an unusual lesson. Let’s talk about your hobby. (I like to visit galleries and theatres)

hәрбер кешенең шулай үз яраткан шөгыле була.

- I don’t want to name the title of our lesson? I want you to guess. Let’s watch a short video. (просмотр фильма)

- Can you name the title of our lesson according to the video? (It’s theatre)

- Балалар, мин сезгә хәзер шигырьләр тыңлатып китәм, ә сез уйлагыз әле, аларның авторлары кем (прослушивание аудиозаписи)

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.
Театр яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.
Театр көлдерәдер, уйнатадыр….

Укучылар: Бөек шагыйребез Г.Тукай язган шигырь.

All the world's a stage,
And all the men and women merely players;
They have their exits and their entrances,
And one man in his time plays many parts,

His acts being seven ages…

Учащиеся: “All the World's a Stage” is written by William Shakespeare.

- Э сезнеңчә театр нәрсә ул?

Укучылар: Театр ул сәнгатьнең иң гүзәл төре, ул кешеләрне көлдерә дә, елата да, уйландыра да. Театр сәхнәсендә артист тудырган дистәләгән образны тамашачы бирелеп карый. Аның белән бергә елый, шатлана. Һәр күренешне йөрәге аша уздыра.

- Now we are going to play an interesting and educational game to speak about Tatar and English theatres. I ask you to be attentive, clever and active!

You have devided into 2 teams. You should ask the questions to each other.

- Дәресебез күңелле, матур үтсен өчен, уен формасында оештырабыз. Экранда сораулар төркемнәргә бүленгән. Сез дә ике төркемгә бүлендегез. Әлбәттә сораулар театр турында татарча һәм инглизчә булачак. Уйларга вакыт бирелә, җавабыгыз тыңлана.

- So, let’s begin. We wish you good luck!

1. When did the first theatre appear in England? (The first theatre appeared in London. It was built in 1599)
2. Казан тамашачысы алдында беренче спектакль кайчан күрсәтелә? (1906нчы елның 22 декаберендә һәм бу көн татар театрының туган көне булып санала).
3. Who was the first-leading actor in England? (The first-leading actor was William Shakespeare).
4. Беренче профессиональ труппаларның исемнәре? (Сәйәр, Нур).
5. Who played women's roles in the plays at that time? (Only men played in the plays).
6. 1939нчы елда бердәм татар дәүләт театрына нинди исем бирелә? (Галиәсгар Камал).
7. How many theatres are there in London? (There are 48 theatres in London.)

8. What famous theatres do you know? (The famous theatres are Kamal, Tinchurina, Kukol'nyi. The Bolshoy theatre, The Britissssh national theatres)

Укытучы: Рәхмәт, укучылар! Булдырдыгыз. It was a nice try!

*Габрахманова Алина Марсельевна*
*учитель английского языка*
*МБОУ «Александровская ООШ»*
*Сармановского района*

**Место и роль родного языка в обучении иностранному языку**

Роль иностранного языка в жизни современного человека возрастает в связи с развитием современных технологий, с ростом бизнес-контактов, развитием туризма и интернета.

Использование родного языка на уроках иностранного языка должно быть осознанным и целенаправленным и быть ограниченно определенным количеством ситуаций, для освоения иностранного языка. Доля использования родного языка зависит не только от знаний учителя, но и от уровня обучения детей.

В начальном звене очень удобно использовать звуки татарского языка. Например: звуки »э «Мэктэп», носовой звук [ŋ] схожи со звуками английского языка, ([s], [t], [h], [r]…или частично совпадают с похожими звуками татарского языка.

При объяснении глаголов настоящего, прошедшего времен, использовать родной язык. Например: «Мин уйнадым футбол кича»»Мин инде футбол уйнадым »обращаю внимание на глагол «уйнадым» на тарском языке, а на английском уже используются ориентиры разных не только времен ,но и аспектов. Past Simple and Present Perfect т.д

С целью проверки понимания услышанного, сказанного надо, что бы ученик повторил мысль на иностранном языке. Например: выражения

:»on a tree», »in a tree». После объяснения, что мы видим дерево как ветку (плоскость), а англичане как крону (сферу), ошибка у всех пропадает. То же самое с выражением «on the Internet»: англичане в своей языковой картине мира работают на интернете, то есть на экране. А есть и схожести: мы, также как и англоговорящие люди, ездим на автобусе. Эти параллели, с родным языков помогают безошибочно применять его в ситуациях общения. Без параллелей с родным языком это сложнее.

При работе с текстом, для понимания сложной части текста, использую родной язык. Вначале звучит сложное сочетание, затем его перевод на родной язык, после чего сразу же повторяется то же сочетание на английском языке. Обычно рекомендуется сигнализировать переход с языка на язык при помощи паузы или изменения тона повествования.

Для быстрого запоминания, на стендах кабинета вывешиваются часто встречающиеся слова или, лучше, фразы и их перевод, неправильные глаголы. You're full of beans today(ты сегодня такой бодрый), It's so much fun( это так весело),»Looks like it»(похоже на это.) и т.д.

Вывод: Родной язык может играть большую роль при изучении иностранного языка. В ходе обучения иностранному языку, ученик, опираясь на родной язык, образует самостоятельную языковую систему, имеющие основные черты родного языка и изучаемого иностранного языка. Учащийся, опираясь на свой родной язык, последовательно, шаг за шагом овладевает иностранным языком.

Литература:

1.Р.Эсхаг. Влияние родного языка на усвоение иностранного зыка. Учебная мотивация школьников// Молодой ученый.-2017.-№7

*Гараева Зульфия Магсумовна,*
*учитель начальных классов*
*МБОУ «Гимназия №11*
*г. Лениногорска» ЛМР РТ*

## Особенности применения интерактивных методов в преподавании татарского языка в русскоязычных группах

Я хочу представить вам интерактивные материалы, которые предназначены для совершенствования татарского языка.

Способов повысить мотивацию учащихся на уроках великое множество. И мы бы хотели рассказать о некоторых из них, которые наиболее часто применяются на уроках татарского языка.

**Игра: «У кого… У меня…»**

Цель игры: Закрепление употребления в речи детей грамматической формы предложного падежа.

Игровой материал: карточки с изображением предметов

Ход игры: детям раздаются карточки. Начинает тот ученик, кому попалась карточка со словом «НАЧАТЬ». Он говорит “Миндә кызыл помидор”, после спрашивает класс, у кого есть слово, которое изображено на нижней части собственной карточки: “Кемдә яшел кыяр»? Остальные ученики смотрят на верхнюю часть картинки. Ученик, у которого изображён «огурец», встаёт и говорит: «Миндә яшел кыяр». Затем он смотрит изображение на нижней части карточки и спрашивает: «Кемдә сары кабак?». Встаёт третий ученик и говорит: «Миндә сары кабак, кемдә кызыл борыч?». Игра продолжается, пока все карточки не будут прозвучаны.

Такие карточки можно выполнить и по другим темам, например «Домашние животные», «Числа» и т.д.

Особенно успешно на уроках татарского языка используется головоломка "Поиск слова", можно даже сказать, что это является

классическим упражнением для обучающихся любого возраста. Выполнение такого задания позволяет не раз "отработать" новое слово: играющий видит и полное написание слова в подсказках, и ищет слово среди других.

На этом сайте  можно создавать головоломки, кроссворды, филворды со словами на татарском языке. Ссылку https://onlinetestpad.com вы видите на экране.

Для развития орфографических навыков используем такие игры, как «Слова рассыпались» — поставить слова в нужные ячейки, составить много новых слов из заданного слова.

Эти карточки актуальны для учеников 1 классов. Дети учатся преобразовывать печатные буквы в прописные. А в данном задании надо ещё и добавить окончания множественного числа.

Здесь дети должны вырезать слова и наклеить к соответствующей картинке, а после раскрасить.

Также дети любят выполнять минипроекты. Данный проект является как завершающий урок по теме «Мин чисталыкны яратам» во 2 классе, «Белем бәйрәме» в 3 классе.

Что бы были интересными задания для развития речи, составления диалогов на сайте www.tondoo.com, можно создать такие комиксы.

Создали ряд видеоуроков на татарском языке по прописям для первоклассников. Я хочу представить один из таких уроков «Прописная буква Ы»

Любой учебный кабинет должен быть оформлен в стиле дисциплины, которая изучается. Я предлагаю подборку материалов для стенда в кабинете. Данные материалы сделают обучение более эффективным, повысят их заинтересованность, сделают занятия увлекательными.

Мы можем сделать вывод о том, что приемов активизации познавательной деятельности учащихся на уроках татарского языка

много. Мастерство учителя и заключается в умении подобрать нужный способ или метод в зависимости от интересов детей, изучаемого материала и сформированности тех или иных умений у учащихся.

*Гилязова Айзиря Анасовна,*
*учитель английского языка,*
*МБОУ «Гимназия г. Азнакаево»*

## Использование арт-технологий на уроках английского языка

Как сделать урок интересным и насыщенным? Какую технологию использовать, чтобы урок стал практико-ориентированным и личностно-значимым для каждого ученика? Как повысить успеваемость и качество усвоения предметного содержания? Любой учитель при подготовке к урокам задает себе эти вопросы.

Применение различных жанров искусства на уроке способно оживить и обогатить учебный процесс новыми красками, сделать педагогический процесс более насыщенным и интересным, а также обеспечить эффективное достижение результатов педагогической деятельности. Именно искусство предлагает один из наиболее популярных и эффективных методов работы на уроке английского языка — метод арт-технологий.

К арт-технологиям относится использование средств иллюстративной наглядности; просмотр видеофильмов, прослушивание музыкальных произведений, создание коллажей по разной тематике, разучивание стихов, рифмовок, песен, художественное сочинение, инсценирование, исполнение различных ролей в диалогах и ролевых играх.

Мне хотелось бы остановиться на одном из интересных приемов арт технологии - это друдлы.


Это изобретение американского автора-юмориста Роджера Прайса и креативного продюсера Леонарда Стерна.

Друдл – это незаконченная картинка, которую нужно додумать или дорисовать. Даже обыкновенный круг или квадрат может стать друдлом.



Посмотрев на эти друдлы, каждый может предложить несколько разных вариантов объяснений к изображению.

Например, здесь кто-то видит пиццу, луну, тарелку супа.



Здесь перекресток, повалившиеся березы, две змеи.



Здесь горы, паук, кошачьи уши.

Эта техника, помогающая развивать творческое и креативное мышление у ребенка и изучать английский язык, которую можно использовать не только как “Warm-up activities”, но и как вариант работы на уроке (изучение, повторение новой темы), а также вид домашнего задания.

Задача ученика состоит в том, чтобы отгадать загадку, зашифрованную в криво нарисованном рисунке на английском языке. Стоит отметить, что для урока берется заранее продуманный «друдл», с несколькими возможными вариантами его интерпретации, а также соответствующий уровню знаний ученика английского языка.

Может быть поставлено несколько задач:

1. Предложить, как можно больше вариантов интерпретации «друдла» на английском языке, работая индивидуально, в группе, команде;
2. Придумать название, описание и действия, происходящие на картинке;
3. Дорисовать данные геометрические фигуры, превратив их в определенный пример быта (напр., тема “House”);
4. Предложить ученикам нарисовать свой «друдл», в то время как остальные учащиеся должны догадаться, что ученик зашифровал;
5. На основе данной картинки придумать логотип и пояснить его.

Что касается среднего звена школы, то подбираются задания, требующие больших знаний и навыков. Например, после изучения темы “My city” и “Prepositions of movements” учитель устно (на английском языке) диктует маршрут по городу, который ученики должны нарисовать самостоятельно, ориентируясь на слух (развивается навык аудирования). При этом учитель использует термины мест в городе и предлоги, которые были пройдены на предыдущих уроках. Как результат у каждого ученика должна получиться небольшая карта города и дети должны проложить маршрут из пункта А в пункт Б, описав его на английском языке. По желанию можно сравнить получившиеся у детей маршруты.

Таким образом, благодаря данной технологии у учеников не только развивается творческое и креативное мышление, логика, но и

пополняется и закрепляется словарный запас английского языка по определенным темам, закрепляется навык говорения (как монолог, так и диалог), так как ученик проговаривает то, что рисует или объясняет, то, что видит на картинке. А самое главное «Друдлы» дают положительные эмоции и желание изучать язык.

*Гумарова Регина Мирзануровна,*
*учитель английского языка*
*МБОУ «СОШ №1 г. Азнакаево»*

## Особенности фонетики татарского языка при изучении английского языка в общеобразовательных учреждениях

«Простота жизни, языка, привычек придает силу нации, а роскошь жизни, вычурность языка и изнеженность привычек ведет к слабости и погибели.»

*Джон Рёскин, английский писатель, художник, литературный критик.*

В современном мире происходит интенсивный рост интеллектуального, творческого потенциала человечества и как следствие возрастает необходимость работы с талантливыми, одаренными, высокомотивированными детьми перед общеобразовательными учреждениями. Федеральный государственный образовательный стандарт ставит перед каждым учителем задачу: раскрыть индивидуальность, самобытность и неповторимость каждого учащегося. Перед школой и мной как учителем-предметником встала проблема: как создать условия для развития одаренности у детей с языковым барьером, тенденция в последние годы такова, что идет увеличение многонациональных учащихся в образовательных учреждениях. В условиях многонациональной страны, где учащиеся являются билингвами, т.е., носителями родного и государственного

языков, вопросы и методы обучения иностранному языку приобретает большую значимость.

Изучение иностранного языка для разных наций в школе имеет свои особенности. Прежде всего, для учащихся, которые с раннего возраста общаются на своем родном языке. Из-за оптимизации сельских школ в стране перестали существовать школы в селе, где обучение проводилось только на татарском языке. Но есть факт, что укрупнение образовательных организаций обеспечивает условия для достижения более высокого качества образования за счет единства образовательной программы, требований, методик и педагогических технологий, а также посредством использования кадровых, материально-технических и финансовых ресурсов. Такой общеобразовательной школой с русским языком изучения предметов является наша школа N1г.Азнакаево. Дети приезжают из девяти деревень: Сапеево, Тойкино, Балтачево, Ассево, Митряево, Уразаево, 1 Мая, Талы-Буляк, Карамалы. Учащиеся разных наций обучаются в школе: татар-483учащихся, русских-30 учащихся, азербайджан-5 учащихся, армян-2 ученика, узбеков-3 ученика, чуваши -2 ученика, корейцев- 2 ученика, немец- 1 ученик. Проблема изучения языков в условии двуязычия нам очень близка.

*Давлетова Венера Асгатовна,*
*учитель начальных классов*
*МБОУ «Гимназия г. Азнакаево»*
*Мирсияпова Гузалия Габдулбаровна,*
*учитель английского языка*
*МБОУ «Гимназия г. Азнакаево»*

## Интегрированное внеурочное занятие
## “Звуки и буквы английского и татарскогоязыков”

Бүгенге көндә мәгълүмат күләме тиз үсә, бу шартларда аны кабул итү һәм фикерләү мөмкинлеге кискен кими. Шуңа күрә гуманитар цикл

предметларының интеграция идеяләре мәктәп практикасына ныграк үтеп керә. Азакы елларда балаларны ике телдә укыту киң таралып килә. Балалар мәктәптә фәннәрне яртылаш туган телендә, яртылаш чит телдә өйрәнсә, алар югары нәтиҗәләргә ирешә алачак диләр. Бу алым балаларга фәннәрне яхшырак үзләштерергә булыша, чит телләрне өйрәнергә ярдәм итә. Баланың эрудициясен үстерә, иҗади потенциалны үстерергә булыша. Фәннәрне тиз һәм җайлы кабул итүдә ярдәм итә.

Интеграцияләнгән дәресләр үткәрү формасы гадәти булмаган, мавыктыргыч. Төрле эш төрләрен куллану укучыларның игътибарын арттыра, дәресләрнең нәтиҗәлелеген үстерә.

Алар бер эш төреннән икенче эш төренә күчү хисабына ару-талуны киметә, танып-белү эшчәнлеген арттыра, игътибар, фикерләү, сөйләм һәм хәтер үсешенә хезмәт итә..

Без сезгә 1 сыйныфта татар һәм инглиз телләрендә дәрестән тыш чарадан өзек тәкъдим итәбез.

Дәрес барышы

1. Шигъри исәнләшү

Хәерле иртә?

Исәнмесез!

Кәефләрегез ничек?

Кояшлы иртә кебек.

2. Психологик уңай халәт тудыру.

Сәлам, дустым!

Хәлләр ничек?

Мин сагындым!

Син килдең!

Мин бик шат!

3. Фонетик күнегү.

Авызда мистер Таң яши.

Ул иртән тора, кояшны күрә

Һәм шакката [O_O_O_O].

Өйләрен җыештыра, келәмнәрен кага. Язычок поднять к небу [d-d-d-d], [t-t-t-t-t].

Кинәт урамда эт ырылдый.Также язычком от зубов назад ведем [r-r-r-r-r-r]

Кемдәр ишек кага, кыңгырау шалтырый Как звук в татарском языке [къ]

Аның дусты керә һәм әйтә Good morning. Good morning.

Аннары алар бергәләп чәй эчәләр.

4. Актуальләштерү.

Укучылар, без сезнең белән нәрсәләр әйттек. (авазлар)

Язуда авазлар нәрсә белән билгеләнә? (хәрефләр)

Әйдәгез без сезнең белән бер уен уйнап алабыз, аның исеме “Аукцион”. Мин сезгә хәрефләр сатам, ә сез күбрәк сүзләр уйлап, ул хәрефләрне сатып аласыз. Уенны башлыйбыз, беренче хәреф м.

5. Физминутка.

Ә хэзер бераз ял итеп алыйк. Миңлебай уенын уйныйк.

Без йөрибез әйләнеп,

Син уртада, Миңлебай,

Син нишләсәң, ни кылансаң,

Без кыланырбыз шулай.

One, one, one:

Little dog, run.

Two, two, two:

Cats see you.

Three, three, three:

Birds in a tree.

Four, four, four:

Rats on the floor.

Комментарий: Таким образом, изучение и знание татарского языка и татарских звуков помогает в изучении английского языка. Сравнение звуков, работа над произношением продолжается в последующие годы. Учащиеся отрабатывают звуки, например, в скороговорках:

Отработка согласного звука [p]

*Peter Piper picked a peck of pickled peppers*

*A peck of pickled peppers Peter Piper picked*

*If Peter Piper picked a peck of pickled peppers*

*Where's the peck of pickled peppers Peter Piper picked?*

(*Питер Пайпер (Дудочник) собрал множество маринованных перцев,*

*Множество маринованных перцев Питер Пайпер собрал.*

*Если Питер Пайпер собрал множество маринованных перцев,*

*То где множество маринованных перцев, которое собрал Питер Пайпер)*

Отработка согласного звука /t/

*To begin to toboggan first, buy a toboggan.*

*But do not buy too big a toboggan!*

*Too big a toboggan is too big a toboggan to buy to begin to toboggan.*

Отработка согласного звука [w], межзубного [з]

*Whenever the weather is cold.*

*Whenever the weather is hot.*

*We'll whether the weather,*

*whatever the weather,*

*whether we like it or not.*

*Ибраһимова Чулпан Рәфәтовна,*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе”нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Мастер-класс**

**“Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә Блум шакмагын куллану”**

Укытучы дөньяга килгәч, аның янына өч фәрештә килгән. Беренчесе әйткән “Син һәрвакыт яшь булырсың, чөнки синең янәшәңдә һәрвакыт балалар булачак.”, икенче фәрештә “Синең күңелең белән матур булырсың, чонки син балаларны гомерең буе матурлыкка өйрәтәсең”, өченче фәрештә “Син һәрвакыт бәхетле булырсың, чөнки синең йөрәгең балаларның җылылыгы белән тулыр”. Менә шул заманнардан бирле без сезнең белән һәрвакыт яшь, күңелебез белән матур һәм бәхетле. Чөнки без укытучылар. Һәркөнне укучыларга йөрәк җылыбызны өләшәбез, һәркөнне купмедер дәрәҗәдә кабат җыеп алабыз. Бүген дә минем сезгә йөрәк җылымны бирәм.

Мастер – классны башлыйбыз. Бердәм Дәүләт Стандартлары тәнкыйди фикер йөрткән шәхес тәрбияләүне үзмаксат итеп куя. Бу максатны үз эченә алган инновацион технологияләрнең берсе ул тәнкыйди фикерләү технологиясе. Тәнкыйди фикерләү – ул мәгълүматны тормыш тәҗрибәсенә таянып кабул итә торган ирекле фикер йөртү дигән сүз. Дәрестә критик фикерләү ысулларын куллану укучыларның фикерләү куәтен үстерә, мөстәкыйльлек тәрбияли, иң мөһиме бала дөрес сорау куярга һәм аңа җавап бирергә өйрәнә.

— Минем сезне тәнкыйди фикерләү технологиясенең бүгенге көндә актуаль булырдай алымнарының берсе – “Блум Шакмагы” алымы белән таныштырасым килә.

Бу алымның авторы америка галиме, педагог, психолог Бенджамин Блум. Ул текстны тиз истә калдыру максатыннан махсус шакмак

кулланырга тәкъдим итә.  Ул шакмакның һәр ягына сорау-бирем язылган.

Шакмакның 6 ягында язылган сорау-биремнәр:

1) Исемен әйт

2) Ни өчен?

3) Аңлат

4) Тәкъдим ит

5) Уйлап тап

6) Уртаклаш

Алымның тәртибе. Укытучы теманы әйтә, һәм шул тема буенча сораулар әзерләп килә. Укучы яки укытучы шакмакны ыргыта һәм кайсы ягы туры килә шул биремне башкара. Ыргыту өчен чикләр юк. Никадәр кубрәк, шул кадәр текст ныграк үзләштерелә һәм истә кала. Бу алымның асылы -төрле типтагы сорауларны кулланып уку дигән сүз.

Блум  Сораулары типлары: гади, ачыклаулы, бәя бирүче, иҗади, практик, аңлатмалы.

Бу алым килеп туган проблеманы төрле яктан фикер йөртеп чишәргә ярдәм итә. Әлеге шакмак белән группалап та, парлап та, аерым да эшләргә мөмкин.

Һәр җавап укытучы өчен укучының белем дәрәҗәсен, активлыгын, теманы ни дәрәҗәдә аңлавын күрсәтә.

Блум алымы универсаль һәм уникаль. Аны барлык фән укытучылары, психологлар, әти-әниләр куллана ала. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә башта бик авыр кебек күренсә дә соңыннан укучылар үзләре бик теләп катнаша башлыйлар. Хәтта бөтенләй җавап бирергә кыенсынган укучылар үзләре сорауны сайлап алып җавап бирәләр. Ә укытучыга бу алым критик фикерләүне үстерергә һәм укучыларны дәрестә актив эшләтергә мөмкинлек бирә.

1. Исемен әйт. Иң гади сораулар. Укучы предмет, күренеш, термин, датаны атарга мөмкин.

2. Ни өчен? Әлеге сораулар сәбәп-җавап мәгънәсендә. Монда әлеге предмет яки герой белән булган вакыйгалар тасвирлана.

3. Аңлат. Әлеге сораулар төгәллек кертүне сорыйю Ачыклый. Алар проблеманы төрле яклап ачарга ярдәм итә.

4. Тәкъдим ит. Монда укучының креатив фикер йөртүе кирәк. Монда укучы үзенең биремен, идеясен тәкъдим итә. Ягъни укучы алган белеменең практикада кулланып булуын раслый.

5. Уйлап тап. Әлеге сорау иҗади.

6. Уртаклаш. Бу бүлектәге сораулар укучыларның анализлау, фактларны аерып чыгару, аларга билге куюга корылган. Бу бүлектә сораулар эмоциягә бай булалар, укучының кичерешләре аңлатыла.

Шакмакны куллануның ике юлы бар:

1. Укытучы сорауны бирә, алдан әзерләп килә.

2. Укучылар сорауны үзләре әзерли.

Башлангыч сыйныф укучылары өчен шакмак кырындагы сорауларны икенче төрле формада төзи алабыз:

1. Тасвирла / Опиши (сурәтлә, текстның яки куелган проблеманың фактларын санап чык, сөйләп чык, атап чык).

2. Ассоцияция китер / Проассоциируй (нәрсәгә охшаган икәнлеген ачыкла);

3. Куллан / Примени (мисаллар китер: сүзтезмәләр, җөмләләр төзе);

4. Чагыштыр / Сравни (аермалы якларын тап);

5. Иҗат ит / Придумай (тема буенча диалог, кечкенә сочинение, синквейн, план төзе һ.б. иҗади эшләр);

6. Бәя бир / Оцени (өйрәнелгән материалның үзенә әһәмиятле якларын билгелә, аргументлар китер, исбатла, уңай һәм тискәре якларын әйтеп кит).

Югары сыйныф укучылары өчен бу алымны язма эшләр оештырганда кулланып була (таблица тутыру рәвешендә). Мәсәлән, әдәби әсәр белән танышкач, укучылар түбәндәге сорауларга җавап бирә алалар.

Мин кабаттан шакмакны алам. Минем сорауларга җавап бирегә сез әзерме .

Исемен эйт. Блум шакмагы.

Ни өчен? Укучыларның критик фикерләвен үстерә.

Аңлат. Кубик.

Тәкъдим ит. Тел дәресләрендә кулланрыга мөмкин.

Уйлап тап. Зур классларда таблица рәвешендә.

Уртаклаш. Мастер-класс ошады.

Рәхмәт яхшы җавапларыгыз өчен. Мастер-классны башлаганда мин сезгә йөрәк җылымны бирдем. Әгәр мастер-класс сезнең күңелегезгә хуш килгән сез дә йөрәк җылыгыз белән бүлешегез.

Онытмагыз. Укытучы һәрвакыт яшь, матур һәм бәхетле.

*Мөхетдинова Резеда Фәвис кызы,*
*Лениногорск шәһәре 3 нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Татар теле һәм әдәбиятын укытуда инновацион технологияләр. Тестлар төзүдә GOOGLE формалар куллану

Татар теле укытучысына ныклы орфографик һәм пунктуацион осталык һәм күнекмәләр булдырырга, укучыларның сүзлек запасын баетырга, аларны әдәби тел нормаларына өйрәтергә, балаларга лингвистик һәм әдәби терминнарны бирергә кирәк. Бу мәсьәләләрне хәл итүдә интернет-ресурслар бәхәссез ярдәмче булып тора. Педагоглар әзер продуктны куллана ала, яисә мөстәкыйль рәвештә үзләре төзи ала.

Бүген мин электрон тестлар, сораштыру(опрос)ларны Google сервисында төзү, тарату һәм җыю тәҗрибәсе белән уртаклашырга телим. Аның ярдәмендә мәктәп программасының теләсә нинди предметлары буенча җиңел генә тестлар һәм анкеталар; шулай ук һәр җавап өчен балларны автомат рәвештә саный ала торган итеп төзергә дә мөмкин.

Google-форма сервисында эшләү өчен мәҗбүри шарт - Интернетка керү мөмкинлеге булу һәм педагог өчен google-аккаунт (Gmail.comда почта). Бу программа укучыларга Google аккаунтсыз эшләргә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, эшкә керешәбез! (Тестны төзү онлайн режимда башкарыла)

1. Google дискны ачабыз, өстә сул почмакта «Создать» төймәсенә басабыз, «Google формалары» - " Буш форма булдырырга"(«Создать пустую форму») төймәсенә басабыз. Форма төзү өчен шаблон автомат рәвештә ачылачак.

2. Тиешле урында формага исем бирергә кирәк. Аңлау өчен сынау тесты ясап карыйк. Ул басма вариантта җыелган. Тест темасын кирәкле юлга куябыз. Әгәр кирәк булса, түбәнрәк урнашкан юлда тасвирлама да өстибез. Мин, гадәттә, анда сыйныфны күрсәтәм.

3. Тестның беренче ике юлында фамилия һәм исемне тутырабыз.

Шаблон 9 вариантта җавап тәкъдим итә: текст (юл), текст (абзац), исемлектән берсе, исемлектән берничә, ачыла торган исемлек, шкала, сетка, дата, вакыт. Фамилия һәм исем өчен без текстны(юлны) сайлыйбыз. Без тестлар өчен форма ясыйбыз, мин тестның һәр соравын мәҗбүри итеп ясыйм, тиешле төймәгә басарга кирәк. Әгәр укучы нинди дә булса сорауга җавап бирергә онытса, форма аның җавабын кабул итмәячәк һәм нинди сорауны төшереп калдырганын

искә төшерәчәк. Укучылар еш кына игътибарсыз һәм форманың бу функциясе бик уңай булачак.

Хәзер тест сораулары һәм җавап вариантлары өстәүгә керешәбез.

4. Уң якта , « Сорау өстәргә» (+ «Добавить вопрос») төймәсенә басып, сорау өчен тәрәзә ачабыз.

5. Шуннан соң сорауны формалаштырырга һәм әлеге сорауга җавап вариантлары өстәргә кирәк.

6. Уңда дөрес җаваплар санына карап шаблон сайлыйбыз: яки исемлектән берне, яисә исемлектән берничәне.

Исемлектән берсе – җавап бирүче тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан бер вариант сайлый яки үз җавабын кертә.

Исемлектән берничә – җавап бирүче кеше бирелгән җавапларның теләсә кайсы янында галочкалар куя ала.

7. Тест биремнәрен төзү өчен бары тик түбәндәге типтагы җаваплар гына туры килә: исемлектән берсе, исемлектән берничә, ачыла торган исемлек. Чөнки бары тик бу вариантларда гына дөрес җавапларга балларны автомат рәвештә бәяләү мөмкинлеге бар. 8. Кирәк булганда, һәр сорау өчен тасвирлама өстәргә була, мәсәлән, бу биремдә нәрсә эшләргә кирәк.

8. Дөрес җавапларны кертү өчен уң як почмактагы шаблон формаларын "карау" (просмотр) функциясеннән файдаланабыз. Фамилиясен, исемен тутырабыз. Үзебез тестны дөрес җаваплар белән узабыз һәм “җибәрү” (отправить) төймәсенә басабыз.

9. Тестны башкарырга сылтама җибәрү өчен шаблон формаларының өске уң ягында "отправить" функциясеннән файдаланабыз. Сылтама значогын сайлыйбыз — короткий URL—скопировать. Сылтаманы балаларга ватсаптагы төркемгә җибәрәбез.

10. Бала сылтама аша кереп җавапларны тутыра, “Отправить” төймәсенә баса. Әзер җавапларны балалар үзләре дә кереп карый ала. Ә

укытучы сакланган формадан җавапларны карау өчен, формага баса, җаваплар бүлегеннән кереп карый.

*Марданшина Ляйсан Марселевна,*
*учитель английского языка*
*МБОУ "ООШ с. Большой Сухояш"*

## Инновационные подходы к повышению педагогической компетенции педагогов в сфере формирования интеллектуальных и творческих способностей детей

Рыночная экономика диктует российскому обществу о том, что нужно проводить интеграцию в мировой инновационный процесс, которому подчинены все области экономики. В согласовании с этим, система образования РФ не может стоять в стороне от глобальных инновационных процессов. Потребность в инновационном развитии и совершенствовании инструментария управления в области образования обусловлены также и жесткой конкуренцией. А значит, инновация рассматривается как единственный инструмент, способный вывести российское образование на качественно новую ступень, а также дает возможность к оптимизации процесса менеджмента в системе образования на территории России [3, с.103].

Инновационное развитие образования, процесс активного совершенствования технологии и инструмента инновационного управления, совершенствования и мультипликации технологии обучения – является неотъемлемым атрибутом образовательной и воспитательной технологии большинства государств. Процесс развития инноваций в системе образования – это базис инновационной и технологической политики государства [2, с.139].

Инновационная деятельность в системе образования ведется в следующих направлениях: инновации в работе с педагогическими кадрами и инновации в содержании образования (использование эффективных педагогических технологий). Целью инноваций в работе с педагогическими кадрами является обеспечение активного участия педагогов в методической работе, что, в свою очередь, способствует совершенствованию системы непрерывного образования и самообразования педагогов через формы инновационной методической работы:

- семинары-практикумы;
- интерактивные формы;
- игровое моделирование;
- проблемные ситуации и др.

Особой популярностью пользуются интерактивные формы. Основной направленностью интерактивных форм является активизация педагогов, развития их креативного мышления, нестандартный выход из проблемной ситуации:

1. Первая эффективная интерактивная форма, введенная в работу с педагогами – тренинг (быстрое реагирование, быстрое обучение). Так как современная жизнь с её многочисленными трудностями как экономического, так и психологического характера требует от человека любой профессии напряжения всех его нравственных и физических сил.

2. Педагогический ринг. Такая форма предусматривает критерии оценки ответов, выступлений и действий участников: общая эрудиция; профессиональные знания, умения, навыки; умение выйти из затруднительного положения, экспромт.

3. Дискуссия – это обсуждение-спор, столкновение разных точек зрения, позиций, подходов [1, с.27].

4. Симпозиум и дебаты.

5. Выставки – ярмарки педагогических идей, аукцион. Благодаря этой форме работы с педагогами создаются условия для публичного представления лучших образцов их профессиональной деятельности, появления новых идей, установления и расширения деловых и творческих контактов с коллегами.

6. Мастер-класс.

Современный педагог сейчас имеет собственный сайт и блог, постоянно пополняемый методическими разработками.

Таким образом, целью инноваций в содержании образования является повышение его качества через инновационные педагогические технологии в формировании интеллектуальных и творческих способностей детей.

Повышение качества образования находится в прямой зависимости от кадров. В современных условиях реформирования образования радикально меняется статус педагога, его образовательные функции, соответственно меняются требования к его профессионально-педагогической компетентности, к уровню его профессионализма. В настоящий момент мы отмечаем, что сегодня востребован педагог творческий, компетентный, способный к развитию умений мобилизовать свой личностный потенциал в современной системе воспитания и развития дошкольника.

Подводя итоги, можно сказать, что грамотно построенная система инновационных форм работы с педагогическими кадрами, - приведет к повышению уровня воспитательно-образовательной работы образовательного учреждения и сплотит коллектив педагогов.

Список литературы.

1. Полат Е.С. Современные педагогические и информационные технологии в системе образования. – М.: Академия, 2008. – 368с.

2. Фокина Н.Н. Инновационные процессы в образовании // ЕСУ. – 2015. – №4(13). – С. 139-143.

3. Шарипов Ф.В. Инновационная деятельность в образовании // Международный журнал экспериментального образования. – 2017. – № 1. – С. 103-107.

*Мияссарова Ляйля Кабировна,*
*учитель начальных классов*
*МБОУ «Джалильская СОШ №2»*
*Сармановского муниципального района*

## Туган тел дәресләрендә Plickers ресурсын куллану

QR кодкарточкаларын  күргәнегез бармы?

Бу мәгълүматны  интерактив рәвештә кодлаштыру алымы. Бүген без аларны туган тел дәресләрендә  Plickers.программасы  исеме астында кулланабыз.

Бүгенге көндә  укучыларның белемнәрен үзләштерү дәрәҗәсен бәяләү темасы актуаль булып тора. Фронталь  рәвештә сорау алып белемнәрне бәяләү формалары шактый күп вакытны сарыф итә.

Заманча технологияләр укытучыга белем үзләштерүне контрольдә тоту өчен бик күп алымнар тәкъдим итә. Шуларның берсе- интерактив Plickers системасы. Ул берничә минут эчендә сыйныфтагы барлык укучының да  белемен берьюлы  тикшерү мөмкинлеге бирә.

Plickers ситемасында эшне оештыру тәртибе: бу системада эшләү өчен Интернетка чыгу юлы булган шәхси компьютер, мобиль кушымта һәм тотрыклы мобиль интернетлы смартфон, QR- кодлы карточкалар, белем бирү материалын визуализацияләү өчен проектор кирәк.

Бу система  ничек эшли? Әлеге системада эшләү QR-кодларга нигезләнгән. Ике үлчәмле штрих-код, ак Һәм кара квадратларда мәгълүмат кодлаштырыла.Укучылар дөрес җавап сайлый һәм

карточканы күтәрә. Укытучысы телефон камерасы белән укучылар күтәргән карточкалардагы QR-кодларны укып чыга. Мөгаллимнең мобиль телефонында урнаштырылган Android идарәсендәгеге «Plickers» мобиль кушымтасы укучыларның кәгазь карточкаларыннан QR-кодларны саный. Онлайн режимда ачык «Plickers» сайты проектор аша экранга сорауны да, нәтиҗәне дә чыгара.

QR-код картасының үзенчәлекләре нинди? Карта кәгазьдә яки картонда эшләнелә. Ул квадрат формасында һәм аның дүрт ягы бар. Аның һәр ягына җавапның үз варианты туры килә (А, Б, C, D). Һәрбер карточкада ул күрсәтелә. Укытучы сорау бирә, укучы дөрес җавап вариантын сайлый һәм карточканы тиешле ягы белән өскә күтәрә. Карточкаларның макеты «Plickers» сайтында тәкъдим ителә. Анда аларның 5 җыелмасы бар, ләкин стандарт (Standard) дигәне иң уңайлысы , ул үз эченә 40 карточканы ала.

Дәрестә Plickers сервисын куллануның кайбер вариантларын карап үтик:

- дәрес башында белемнәрне актуальләштерүгә һәм системалаштыруга;
- дәрес уртасында - күнегүләр дәрестә өйрәнелгән яңа алымнарны һәм алгоритмнарны үзләштерүгә;
- дәрес ахырында яңа белемнәрне ныгытуга бирелә.

Кушымта белән эшли башлаганчы укытучы www.plickers.com. сайтындагы кушымтада теркәлә, аннары ресурс битенә керә һәм аны куллану уңайлылыгы өчен инглиз теленнән тәрҗемә итә. Шуннан соң кушымтада теркәлү турында почта тартмасына хәбәр теркәлә . Параллель рәвештә Play marketтан смартфонга «Plickers» мобиль кушымтасын күчереп алабыз һәм системага үзебезнең логин һәм пароль белән керәбез. Теркәлү турында хәбәр расланганнан соң кушымта

тәрәзәсе ачыла, анда бирелгән тәкъдимнәр буенча турыдан-туры эш алып барыла

Шулай итеп, интерактив тест үткәрү «Plickers» технологиясе укучылар арасында фронталь сораштыру үткәргәндә гади һәм уңайлы сервисларның берсе. Мобиль кушымта белән эшләү вакыт буенча минимумга кадәр кыскартылган - сораштыру нәтиҗәсен алу дәресләрдә бара, укучыларда смартфоннар яки компьютерлар булуны таләп итми. Җаваплар реаль вакыт режимында тикшерелә һәм бәяләнә. Нәтиҗәләр мәгълүматлар базасында саклана. Укытучы дөрес һәм дөрес булмаган җавапларны һәм аларның авторларының статистикасын тактада ук күрә ала.

*Назмутдинова Резеда Ринатовна,*
*учитель английского языка,*
*МБОУ «СОШ№5 г. Азнакаево»*

## ***Формирование межкультурной коммуникативной компетенции учащихся аудиовизуальными средствами***

Возрастающие требования к уровню владения иностранным языком учащихся обусловливают необходимость поиска новых технологий обучения иностранным языкам. Это связано с необходимостью формирования у учащихся способности участвовать в реальной межкультурной коммуникации и со стремлением соответствовать единым европейским стандартам в образовании. В общеевропейских компетенциях владения иностранным языком выделены следующие межкультурные знания и умения:

- способность соотносить свою собственную и иноязычную культуры;
- восприимчивость к различным культурам, умение гибко использовать разнообразные стратегии для установления контакта с представителями иных культур;

- умение выступать в роли посредника между представителями своей и иноязычной культуры и эффективно устранять недопонимание и конфликтные ситуации, вызванные межкультурными различиями.

Общеевропейским установкам созвучны положения ФГОС основного общего образования.

Таким образом, межкультурный аспект находит широкое отражение в нормативных документах общеобразовательной школы, что свидетельствует о необходимости формирования межкультурной коммуникативной компетенции учащихся.

Целью данного маленького исследования можно назвать определение потенциальных возможностей аудиовизуальных средств для формирования межкультурной коммуникативной компетенции учеников.

В настоящий момент аудиовизуальные средства широко применяются для решения достаточно широкого круга образовательных задач. В целом выделяются в качестве ведущих следующие возможности данных средств (в особенности видео) на уроке иностранного языка:

- способствуют интенсификации процесса обучения иностранному языку, позволяя сократить время для изучения данной темы ;
- увеличивают эффективность усвоения лингвострановедческого аспекта, невербальных средств выражения, характерных для народа страны изучаемого языка;
- позволяют сделать объяснения самых сложных явлений нагляднее и убедительнее, чем сам педагог;
- воссоздают реальную ситуацию общения носителей языка;
- служат содержательной основой речи учащихся;
- представляют в адекватном виде реальную речевую деятельность носителей языка;

- дают адекватное отражение страноведчески важных аспектов жизни страны изучаемого языка;

- служат средством, обеспечивающим дистантное погружение обучаемых в языковую среду.

Вышеперечисленные возможности аудиовизуальных средств на уроке иностранного языка наглядно демонстрируют, что необходимость их использования по-разному воспринимается не только учителями, но и многими учеными-методистами.

Видеозаписи имеют больший, по сравнению с печатными и звучащими текстами, лингводидактический потенциал, поскольку благодаря видео наглядно демонстрируется естественное (аутентичное) протекание процесса межкультурной коммуникации.

Благодаря этому появляются неограниченные возможности для проведения анализа, построенного на сопоставлении культурных реалий и особенностей поведения людей родного и иного лингвосоциумов в различных ситуациях межкультурного общения.

Список литературы:

1. Барменкова О. И. Видеозанятия в системе обучения иностранной речи // ИЯШ. 1999. №3.С. 20–25.

2. Елизарова Г. В. Культура и обучение иностранным языкам. СПб.: Каро, 2005.352с.

3. Иванова Л. А. Формирование медиакоммуникативной образованности школьников-подростков
средствами видео (на материале уроков французского языка): Дис. канд. пед.наук.Иркутск,1999.246с.

4. Костомаров В. Г., Митрофанова О. Д. Методическое руководство для преподавателей русского языка иностранцам. М., 1988. 157с.

5. Общеевропейские компетенции владения иностранным языком: изучение, обучение, оценка /Подред.К.М.Ирисхановой.МГЛУ,2005.247с.

6. Писаренко В. И. Методика использования видеоматериалов в обучении второму иностранному языку (на материале французского языка в неязыковом вузе): Автореф. дис. канд.пед.наук.Таганрог,2002.26с.
7. Федеральный государственный образовательный стандарт общего образования. Среднее (полное)общее образование: Проект. М.: Российская академияобразования,2011.38с.
8. http://mon.gov.ru/files/materials/7195/1897.pdf — Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования от 17 декабря 2010 г.

*Насипова Гүзель Шайхетдиновна,*
*учитель начальных классов*
*МБОУ «Гимназия г. Азнакаево»*

## Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә критик (тәнкыйди) фикерләү алымнарын куллану

ФГОС таләпләре буенча белем бирүнең төп максаты-укучыларга белемнәр, күнекмәләр бирү генә түгел, ә аның үзен мөстәкыйль рәвештә белем алырга һәм бу белемнәрне тормышта иҗади кулланырга өйрәтү. Бу максатны үз эченә алган инновацион технологияләрнең берсе-критик (тәнкыйди) фикерләү технологиясе.

Фикерләү-ул баш миендә мәгълүматны эшкәртү процессы. Критик фикерләү, беренче карашка, тәнкыйди фикер йөртү, тәнкыйть күзлегеннән карау дип кабул ителә. Ләкин белем бирү системасында бу төшенчә стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камиллеген ассызыклый. Ул-интелектуаль (гамәли) эшчәнлек төре: мәгълүматны кабул итү, төшенү, хәтердә калдыру, иҗади, интуитив фикерләү.

Тәнкыйди фикерләү технологиясендә укытучы эшчәнлеге-ул:

1. Укучының эшчәнлегенә юнәлеш бирә.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә этәргеч ясаучы шартлар булдыра.

3. Төрле фикерләрне каршы куя.

4. Нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Ә инде укучы эшчәнлеге түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Куелган проблеманы чишә.

2. Дәлилләр эзли.

3. Башкаларның фикерен тыңлый.

4. Бәхәсләшә.

5. Бәя бирә.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора: өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту → төшенү (аңлау) → рефлексия.

**Тәнкыйди фикерләү технологиясе ысуллары күптөрле**. Бүгенге чыгышымда шуларның берничәсенә 3 нче сыйныф әдәби уку дәресендә Василий Радловның "Карга хәйләсе" һәм Лев Толстойның "Зирәк чәүкә" мәсәлләрен өйрәнү үрнәгендә тукталып үтәсем килә.

**Дәреснең өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту этабында**

1 «Синквейн» ысулын кулланып була.

Балаларга беренче юлыннан башка синквейн тәкъдим ителә . Сораулар бирелә:

- Узган дәрестә нинди әдәбият жанры белән таныштык? Игътибар белән укыгыз һәм яшеренгән сүзне табыгыз.

гыйбрәтле, көлкеле

файдалы киңәш бирә, акыллы булырга өйрәтә, үгетли

кечкенә, гыйбрәтле, акыл өйрәтүле хикәя

үгет-нәсыйхәт

-Әлбәттә, мәсәл.

- Димәк, бүген без матур мәсәлләр дөньясына сәяхәтебезне дәвам итәбез.

2. Киләсе ысул - «Кәрзин» ысулы.

- Мәсәлләрне укый башлаганчы «Дөрес җаваплар кәрзине» уены уйналына.

- Төркемнәрендә эшләячәкбез. Һәр төркем 1 сорау ала, аңа 3-4 җавап тәкъдим ителә, шуның дөрес булганын гына сайлап алырга кирәк.

Төркемнәр өчен биремнәр бирелә:

1.Мәсәл – ул

• кыска шигъри хикәя;

• кызыклы хәл турында әсәр;

• гыйбрәтле, акыл өйрәтүле кыска хикәя.

2. Мәсәлнең геройлары

• кешеләр;

• хайваннар, кошлар;

• кешеләр, хайваннар.

3. Мәсәл

• хәйләкәр булырга өйрәтә;

• тормыш тәҗрибәсенә ия булырга өйрәтә;

4. Мәсәлдә

• мораль бар;

• мораль юк, һәркем аны үзе уйлап таба;

• мораль кирәк түгел

5. Мәсәл өлешләре:

• хикәяләү һәм мораль

• кереш, төп өлеш һәм йомгаклау өлеше

Балалар төркемнәр эшләрен яклыйлар һәм кәрзинне тутыралар.

Аңлатмалы сүзлектән мәсәл сүзенең дөрес аңлатмасы укыла һәм нәтиҗә ясала:

Димәк, мәсәл – чәчмә яки шигъри формадагы үгет-нәсыйхәт бирүче кечкенә генә күләмле әсәр.

- Ә кем әйтә ала, нәрсә ул мәсәлнең морале? -дигән сорау бирелә

Мораль-мәсәлнең нәтиҗәсе. Моральдә акыл, әдәп - әхлакка өйрәтә торган фикер үткәрелә.

II. **Дәреснең төшенү, аңлау этабында** «Концептуаль яки чагыштыру таблицасы» ысулы бик отышлы һәм уңай дип саныйм. Вертикаль буенча чагыштыру өчен нигез булып тора торган билге урнаша, горизонталь буенча чагыштырыла торган мәсәлләр урнаша.

| | Л. Толстой<br>“Зирәк чәүкә” | В. Радлов<br>“Карга хәйләсе” |
|---|---|---|
| Мәсәл геройлары | | |
| Композиция | Мораль мәсәлнең ... язылган | Мораль мәсәлнең ... язылган |
| Мораль кайсы герой тарафыннан чыгарыла? | | |
| Морален языгыз | | |
| Әсәрне рольләргә буленеп укып буламы? | | |
| Нинди формада язылган? (чәчмә, шигъри) | | |

Укучылар мәсәлләрне укыйлар һәм таблица баганаларын тутыралар.

2. «Кубик» ысулын балаларны сәнгатьле укырга өйрәтү өстендә эшләгәндә кулланып була.

Кубик кырларына шаяртып, моңсу, шатлыклы, кайгылы, аптырап, җитди рәвештә дип язылган. Балалар кубикны тәгәрәтеп,үзләренә уку төсмерен табалар һәм укып күрсәтәләр.

III. **Дәреснең рефлексия этабында тәнкыйди фикерләү технологиясенең «Төсле тамгалар» ысулы** бик кулай.

Карточкалар белән эш алып барыла һәм балаларга бирем бирем бирелә:

-Түбәндәге мәкальләрне укыгыз. Башта икенче мәсәлгә мораль булырлык мәкальне табыгыз. Аның астына кызыл каләм белән сызыгыз.

-Аннары мәсәлдәге геройларга туры килгән мәкальне табыгыз. Аның астына зәңгәр каләм белән сызыгыз.

Мәкальләр:

1. Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
2. Сабыр төбе сары алтын.
3. Кем эшләми, шул ашамый.
4. Сөйләп күрсәткәнче, эшләп күрсәт..
5. Яхшылык ташны да эретә
6. Һәр максатка чара бар.

**2. Өй эше** биргәндә «Укытучыга хат» ысулын кулланып була.

Укытучы укучыларга “Укытучыга хат” язарга тәкъдим итә

Хат язу өчен белешмәлек үрнәге бирелә.

1. Мин ______________________________мәсәлен укыдым.
2. _____________________________________ истә калды.
3. _____________________________________________ ошады.
4. __________________________________________ ошамады.
5. Минем эмоциональ халәтем __________________________
6. Бу мәсәл мине_________________________________ өйрәтте.

Шулай итеп тәнкыйди фикерләү технологиясе шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудырып кына калмый, баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Укучы дәрестә өйрәнелә торган материалның асылына төшенеп, тулысынча анализлый, нәтиҗәләр чыгара. Бу технологиянең нигезендә

стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, катлаулы проблемаларның яңа чишелешен табу һәм иҗади эшләү ята. Бу - акыл эшчәнлегенең гадидән катлаулыга таба үсешен тәэмин итәргә ярдәм итә.

*Рахманова Фәния Изаиловна,*
*"Азнакай шәһәре гимназиясе"нең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

**Башлангыч сыйныфларда "Фишбоун" алымын куллану"**

Мәгариф өлкәсендә тирән үзгәрешләр барган хәзерге заманда, укытучы алдында куелган бурычлар арасында иң өстенлекле проблема булып укыту һәм тәрбия бирүдә яңа технологияләр куллану тора.

Икенче буын Стандарты кертелү белән бурычларның берсе булып укучыларда тәнкыйди фикерләү тора. Бүген укучылар үзаллы фикер йөртергә, күп төрле мәгълүмати чыганаклар белән эш итә белергә тиеш, бу-заман таләбе. Дәрестә тәнкыйди фикерләү ысулларын куллану балаларның фикерләү куәтен үстерә, мөстәкыйльлек тәрбияли, иң мөһиме бала дөрес сорау куярга һәм аңа җавап бирергә өйрәнә.

Ә нәрсә соң ул тәнкыйди фикерләү?

"Дөньяга акыл белән караган кешегә генә, дөнья акыл белән карый." дигән француз язучысы Виктор Гюго.

Тәнкыйди фикерләү-бу тәнкыйть белән фикер йөртү ысулы, фикерләү функцияләренең иң югары дәрәҗәсен үзләштерү, монда анализ, синтез һәм мәгълүматларны чагыштырып карау керә, сәбәби-тикшеренү элемтәләрен табу, нәтиҗә ясый һәм проблемаларны чишә белү.

Тәнкыйди фикерләүне үстерүче нәтиҗәле алымнарның берсе дип мин "Фишбоун" алымын исәплим. Фишбоун - күренекле япон галиме Исикавы Каору диаграммасы. Аның асылы булып объект һәм аңа тәэсир

итүче факторлар арасында сәбәби-тикшеренү элементәләрне табу. Фишбоун – әйләнә тирә дөнья һәм әдәби уку дәресләрендә бик уңышлы кулланыла. Бу стратегия укучыларга гомуми проблеманы сәбәпләр һәм дәлилләргә аера белергә мөмкинлек бирә.

Бу схема 4 өлештән тора: баш, югары һәм түбән сөякләр, койрык.

Башка борчыган сорау, проблема куела. Югары сөякләр – проблемага китерүче сәбәпләр, түбән сөякләрдә сәбәпләрне ачыклаучы фактлар, дәлилләр китерелә, ә коерыкта нәтиҗә языла.

Фишбоун схемасында барлык язулар да кыска булырга тиеш.

Әйдәгез бергәләп Фишбоун ысулын әдәби уку дәресендә Роза Хафизованың “Күңел күзе” хикәясен йөрәнүдә кулланыйк.

Эшнең асылын аңлар өчен сезне әсәрнең эчтәлеге белән кыскача таныштырасым килә. Яз көне Камилне әтисе урманга алып бара. Алар урманга керү белән Камил нарат агачларының шаулавына игтибар итә. Малайда, агачлар телен аңлыйсы иде, дигән теләк туа. Шулчак нарат башында тиен күренә, күркә алып җиргә ата. Камил тиенгә көлеп карый, мин синңа тимим, ди. Тиен тиз арада юкка чыга. Ә әтисе әйтә: иптәшләренә: “Камил –яхшы малай, урман җәнлекләренә тими”, дип әйтергә ашыкты ди. Аннары алар ландыш чәчәкләрен күрәләр. Камил сак кына берничә чәчәк өзә, тамырлары белән йолыкмый. Шулай бара торгач алар сынып суы аккан каенны күрәләр, аны каен суы җыйган кешеләр шушы хәлгә китергән була. Камил каенны бик кызгана. Шулчак Камил белән әтисе янындагы ботакта бер кош ярсып чыркылдарга тотына. Бераз күзәткәч Камил белән әтисе кошларга комачаулаганнарын аңлыйлар һәм читкә киттеләр. Хикәя әтинең сүзләре белән тәмамлана: Урманны күңел күзе белән күрергә өйрәндең.

Балалар әсәрнең эчтәлеге белән танышканнан соң күзәтүчәнлек, тәнкыйди фикерләүне үстерү, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү максаты белән әнгәмә ярдәмендә фишбоун схемасы тутырыла.

У.: Хикәянең исеме ничек? (“Күңел күзе”)

Күңел күзе... Нүрсә соң ул? Күзнең ни икәнен беләбез, ә күңелнең күзе буламени? Безнең проблема: Нәрсә ул күңел күзе? Әйткәнемчә, проблема балыкның башына языла.

У.: Камилнең әтисе әсәрнең башында ни диде? Укыгыз. (“Урман – зур ул, серле ул, күңел күзе белән карасаң гына, бөтен нәрсәне күрерсең”. Тагын өстәп тә куя: “Күңел күзе белән карамасаң, маңгай күзе берни күрми ул. Шуңа күрә борынгылар, маңгай күзе – ботак тишеге, дигәннәр”, – ди.) Әйдәгез әле Камилнең әтисе белән урманга килеп күңел күзе белән түгел, ә бәлки маңгай күзе белән нәрсәләр күрүен искә төшерик. Аларны без югары сөякләргә урнаштырырбыз. (текстта бу сүзләр астына сызылган).

1. Агачлар.
2. Тиен.
3. Ландыш чәчәкләре.
4. Каен.
5. Кош.

Түбән сөякләрдә-өстә язылган төшенчәләргә ачыклык кертүче фактлар, дәлилләр языла.

У.: Ә хәзер, текстка таянып югарыда китерелгән сүзләрне ачыклыйк. Малайның бигрәк тә хис-тойгыларына, кичерешләренә, уй-фикерләренә игътибар итик. (Сораулар ярдәмендә түбәндәге сөякләргә язулар билгеләнә):

Агачларның шаулавын ишеткәч, малайда нинди теләк туа?

1. Агачлар телен аңлыйсы килә.

Аннары соң Камил тиенне күреп ала. Ул тиенгә нинди мөнәсәбәттә?

2. Камил урман җәнлекләренә тими.

Шуннан соң алар ландыш чәчәкләренә игътибар итәләр. Камил монда нишли?

2. Тамырлары белән йолыкмый, күп өзми.

Сынган каенны күргәч Камил нәрсәләр кичерә?

3. Каенны бик кызгана.

Ни өчен кош ярсып чыркалдарга тотынгач Камил әтисе белән читкәрәк киттеләр?

4. Кошларга комачауларга ярамаганын аңлады.

Камил урманда каранып кына йөрми, ул бар нәрсәгә игътибар итә, тиен белән сөйләшә, каенны кызгана.

У.: Хикәянең азагында әтинең сүзләрен укыгыз әле. (Аның каравы, урманны күңел күзе белән карарга өйрәндең.) Ничек икән соң ул: “Урманны күңел күзе белән карарга өйрәндең”?. Сез ничек аңладыгыз?

(Күңел күзе - эчке тоемлау, хис – кичерешләр).

Балыкның коерыгы — башта куелган сорауга җавап була.

Шулай итеп, йомгаклыйк: проблема куелды; сәбәпләр билгеләнде; ачыклык кертелде; нәтиҗәләр ясалды.

Балык сөяген тутырып бетергәч, аны алтын балыкка әйләндерергә мөмкин. Ә алтын балык теләкләрне тормышка ашыра. Безнең теләгебез: бөтен кешеләр дә матур, бай табигатебезгә күңел күзе белән карый белсеннәр иде, аны сакласыннар, якласыннар иде. (слайд №7)

Фишбоун алымын куллану укучыларның текстны анализларга, төп вакыйгаларны ачыклый белергә, аларның сәбәпләрен табарга һәм эшләгән эшкә нәтиҗә ясый белергә өйрәтә. Бигрәк тә Фишбоун бүгенге мәктәпнең төп бурычын үти: иҗади һәм тәнкыйди фикерләүне үстерә.

Без – укытучылар үзебезнең укучыларыбызны тәнкыйть белән тыңларга һәм кабул итәргә, яңа мәгълүматны уйлап анализларга, үз-үзеңне үстерү остендә тәнкыйть белән эшләргә өйрәткән очракта гына, безнең укучыларыбыз хәзерге заманда яшәргә әзер дип ышанып әйтә алабыз.

*Садриева Фарида Азат кызы,*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе”нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

**Заманча технологияләрне куллану туган (татар) телне укыту процессын тагын да нәтиҗәлерәк итә**

Гадәти укыту технологияләре иҗади эшмәкәрлеккә тулысынча ачылырга бирми, ә хәзер илгә киләчәген алдан күргән, планлаштыра алган, тормышка ашыру юлларын ачык төсмерләгән шәхес кирәк, диләр. Укып алган диплом гына тормышта үз урыныңны табуга гарантия була алмый икән хәзер. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеген бөтенебез дә белә анысы. Мәктәпләрдә шундый шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр куллану ярдәм итә. Сиксәненче елда хезмәт юлымны башлап җибәргән татар мөгаллимәсе буларак, мин моны аңлыйм ... Ярты гасырга якын вакыт узып бара шул... Пенсия яшен узып китсәм дә, мин, үз һөнәремә тугърылыкны саклап, бүген дә балалар арасында! Замана белән бергә атламый хәлең юк.

Бөтендөнья белем бирү процессының мөһим һәм тотрыклы тармагы – белем бирүдә заманча информацион технологияләр куллану. Соңгы елларда илебез мәктәпләрендә күпчелек предметлардан белем бирүдә компьютер техникасы һәм башка информацион технологияләр ешрак кулланыла башлады.

Бу информатизация белем бирү процессына сизелерлек йогынты ясый. Ул белем бирү процессын үтемлерәк итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материалны аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

Нәрсә соң ул информацион технология?

**Белем бирүдә информацион технология** – компьютер техникасы һәм программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны укучыларга әзерләү һәм җиткерү процессы.

Белем бирүдә кулланыла торган информацион технологияләр ике төргә бүленә: **техник чаралар** (компьютер техникасы һәм бәйләнеш чаралары), төрле максатта кулланылган **программа чаралары**.

Әгәр мин дәресне оештырганда компьютер кулланырга уйлыйм икән, мин югарыда әйтелгән чараларның мөмкинчелекләрен һәм куллану тәртибен белеп эш итәргә тиешмен.

Ни өчен туган тел дәресләрендә компьютер техникасы куллану кирәк соң? Информацион технология чаралары кулланып, дәрестә нинди мәсьәләләр чишеп була? Сораулар, сораулар... Сорауларга җавап эзлим...

Беренчедән, укучыларда туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту. Мәктәптә укытылган башка фәннәр арасында туган тел дәресләренең абруен күтәрүдә, тәҗрибә күрсәткәнчә, компьютер техникасы куллануның да роле зур бүген. Шулай ук

- шәхес тәрбияләү
- фикерләү сәләтен үстерү
- эстетик тәрбия бирү
- информацион культура тәрбияләү
- укытуның сыйфатын күтәрү
- предметара бәйләнеш булдыру
- укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уятуда информацион технологияләрнең йогынтысы зур.

Эзләнү-тикшеренү өстендә эшләгәндә, укучыларга еш кына иҗади өй эшләре бирәм, яисә реферат, дәрескә өстәмә материаллар алып килергә кушам. Мондый очракта алар үзләре татар телендә булган сайтлардан материаллар эзләп табып әзерләп алып киләләр.

Туган тел дәресләрендә информацион технологияләр укытучыга нинди методик мөмкинчелекләр бирә соң?

-дәрес материалын күз алдына китерү ;

-төрле модельләр, таблицалар төзү;

-үз-үзеңне тикшерү булдыру.

Мин тест формасындагы бирем эшләтәм. Аннан соң укучылар экранга карап үз-үзләрен тикшерәләр һәм үз эшләрен бәялиләр.

Әзер дискларда сүзлекләр очратканым булмады. Без еш кына кирәк булганда сүзлекләрне интернет челтәре аша табып алабыз.

Презентация формасында эшләнгән слайдларны дәресләребездә еш кулланабыз. Сөйләм теле үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик уңайлы.. Г.Тукай, М.Җәлил, Г.Ибраһимов, Р.Миңнуллин кебек шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү дәресләре өчен, грамматиканы өйрәнү өчен эшләнгән әзер презентацион программалар да бар.

Бүгенге көндә күпчелек мәктәпләрдә күп мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар, җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Мин дә бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшемдә кулланырга тырышам, әлбәттә. Әмма һәрбер дәресне дә информацион технологияләр кулланып үткәреп булмый, мондый дәрескә әзерлек укытучыдан күп вакыт таләп итә.

Укытучының тере сүзен бернинди компьютер да алыштыра алмый дип уйлыйм. Туган тел дәресләрен укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый. Чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барырга тиеш. Башкача мөмкин дә түгел. Хәер, бу минем фикерем...

Туган телем минем! Туган телем!

Туган телем, диеп кабатлыйм.

Туган телдә сөйләп, туган телне зурлап,

Якты киләчәккә мин атлыйм!..

*Тинбакова Римма Варисовна,*
*Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## ***Башлангыч сыйныф укучыларына татар телен өйрәткәндә образлы күзаллау алымнары (эш тәҗрибәсеннән)***

Кече яшьтәге балалар дөньяны күзәтеп, тоеп, аерым алганда сенсорик тоеп, кабатлап карап таныйлар. Телгә өйрәнгәндә дә алар сүзләрне күреп түгел, ә ишетеп, мәгънәсен аңларга тырышылар, аерым сүзләрнең предметны, аның билгесен яки хәрәкәтне белдерүләрен дә олылардан нәкь менә ишетү, аралашу аша, тышкы дөньяны күзәтү аша аңлыйлар, ишеткән сүзләрен кабатлап, урынлы кулланырга өйрәнәләр. Шул рәвешчә, сүзлек байлыкларын арттыралар һәм телгә өйрәнәләр.

Башлангыч сыйныфта укучы рус телле балаларга татар телен өйрәтүне мин сөйләм теле аша бирергә тырышам. Монда хәрефләрне, язылган сүзләрне күрү кирәкми. Иң беренче итеп, бала аларны ишетергә тиеш. Моның өчен балаларның күзаллауга бик оста булуларыннан файдаланам. Бу нәрсә дигән сүз? Төрле темага кагылышлы сүзләр запасын булдыру өчен, без шигырьләр ятлыйбыз. Гади генә итеп түгел, ә хәрәкәтләр белән. Предметның (мәсәлән, куянның) атамасын, билгеләрен, хәрәкәтләрен белдергән сүзләрне истә калдыру өчен, куллар, аяклар белән төрле хәрәкәтләр ясыйбыз. Укучылар шул хәрәкәтләргә бәйле сүзләрне бик тиз һәм җайлы истә калдыра. Аерым бер хәрәкәтнең билгеле бер сүзне аңлатуын үзләштерә. Шушы рәвешле,

образларны күзаллау аша сүзлек запасын булдыра, телгә өйрәнә. Мәсәлән:

| Өйрәнелә торган шигырь | Сүзләргә бәйле хәрәкәтләр |
|---|---|
| Ак куянкай утырган , | Куллар баш өстенә куян колаклары рәвешендә куела, чүгәләп утырыла. |
| Колакларын селкетә. | Колак-куллар хәрәкәтләнә. |
| Менә шулай, менә шулай<br>Колакларын селкетә. | Колак-куллар исбат иткән характерда хәрәкәтләнә. |
| Куян туңа башлаган,<br>Аякларын җылыта. | Балалар үзләрен кочаклап туңу хәрәкәте ясыйлар. |
| Менә шулай, менә шулай<br>Аякларын җылыта.<br>Куян һаман да туңа, | Аякларын уалар. |
| Сикергәләп тә куя. | Өшү, калтырау хәрәкәтләре. |
| Менә шулай, менә шулай<br>Сикергәләп тә куя.<br>Кемдер аны куркытты, | Сикерәләр. |
| Ул урманга элдертте. | Тиз генә урыннарга утыралар. |

Мондый характердагы шигырьләрне физкульт-минут вакытларларында да кулланырга була. Татар телен өйрәнүгә әз вакыт каралган чорда бу бигрәк тә актуаль, дәреснең һәр минуты телне өйрәнүгә юнәлтелә. Әлбәттә инде, әлеге шигырьләр ятланылып беткәч, аларны дәрес башында, дәрес ахырында да хор белән сөйләтергә була. Бу тел дәресләренә кергәч, уңай психологик халәт тудырырга булыша, без аны “татар телендә сөйләшүгә күчәбез” дип атыйбыз.

Төрле темаларга кагылышлы шигырьләр җитмәгән очракта, аларны үзем дә иҗат итәм. Шулай итеп, телне өйрәтүдә образларны күзаллау

аша без телгә дә гаять тиз өйрәнәбез, укучыларның фикер йөртү сәләтен, хәтерен дә яхшыртабыз, акыл үсешен дә тәэмин итәбез, бәйләнешле сөйләм теле дә үсә. Балаларда уйлау, тапкырлык, зирәклек, игътибарлылык, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар да камилләшә, ныгый.

*Фазлыева Гөлфинә Нашатовна,*
*“Азнакай шәһәре 7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы*

## ***А.А.Пластовның “Печән өсте” картинасына тасвирлама бирү***

“Әгәр дә яхшы яшисең килсә, үз эшеңне яхшылап башкар, синең эшеңне башкалар да хөрмәт итсеннәр” (Каюм Насыйри)

Мөгаллимнең эшен яхшы итеп башкаруы укучыда фәнгә, телгә кызыксыну уята. Татар теле укытучысы укучыларның телне камил белүе һәм аны сөйләмдә куллану дәрәҗәсен күтәрү өстендә эшли. Бу эш барышы бүгенге көндә **актуаль**, чөнки Татарстан Президенты Указы белән 2021 нче ел Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Шул максаттан педагогик тәҗрибәм белән уртаклашу өчен “Ел укытучысы 2020” бәйгесенең зона турында 7 нче сыйныфның татар төркемендә үткәргән татар әдәбияты дәресенең барышы белән таныштырам.

Дәрес темасы: А.А. Пластовның “Печән өсте” картинасына тасвирлама бирү.

Дәрескә куелган бурычларны хәл итү өчен укыту технологиясенең тәнкыйди технология, интеллект карта алымын кулландым. Укучылар коллективта, парларда һәм төркемнәрдә эшләделәр.

Дәрес уку эшчәнлегенә уңай мохит тудыру, уку теләге булдыру өчен хат белән башланды. Хат белән танышканнан соң, укучыларга репродукциянең төсләрен яңарту эшенә алынырга тәкъдим ясалды.

Дәреснең уку мәсьәләсен өлешләп чишү этабында рәссам биргән төсләрне яңарту өчен картинаның оригиналын күрергә кирәк. Оригиналны бары тик  Мәскәү шәһәрендә урнашкан Яңа Третьяков галереясында гына күрергә була. Төркемләп утырган укучылар **ноутбукларда сылтама белән галереяга керәләр.** Галереяның 28 нче залы буенча хәрәкәт итеп, картинаның оригиналын табалар. Ул рәссам А. А. Пластовның "Печән өсте" картинасы.

Картинаны тасвирлау өчен өч эш төркеме оештырыла. 1нче төркем картинаның алгы планын, 2 нче төркем урта планын, 3 нче төркем арткы планын тасвирлый. Төркемнәрдә эш төрен бүлешеп, һәркем үз ролендә эш башкара. №1-техник, №2 -  язучы, №3 - фикер бирүче, №4 – яклаучы. Эш интеллект карталарда башкарыла. Картинаны тасвирлау өчен төп интеллект карта тактага эленә. Аның уртасына тема язылган ("Печән өсте") һәм өч тармак чыккан. 1 тармак - алгы план, 2 тармак - урта план, 3 тармак - арткы план.

Һәр төркемнең үз интеллект картасы бар. 1 нче төркемнең алгы план дип язылган, 2 нче төркемнең урта план, 3 нче төркемнең арткы план дип язылган. Уртада шушы төркем өчен төп тема языла. Темадан тармаклар-уклар чыга. Бу тармакларга укучылар картинаның үзләренә тиешле өлешендә нәрсәләр күрәләр, шуларны язалар. Бу тармаклардан тагын уклар чыгарып, өстәмә фикерләрен язалар.

Эш төркемнәрдә башкарыла. Һәр укучының вазифасы бар. Техник картинаның үз өлешен якынайтып күрсәтә, язучы интеллект картаны тутыра, фикер бирүче аңа булыша, сүзләрне табыша. Яклаучы эш барышын күзәтә, өстәмәләр кертә. Эш барышында сүзләр язарга, рәсемнәр ясарга да мөмкин.

Һәр төркемнең картинаны тасвирлау өчен интеллект карталары әзер булгач, ул эшләрне сөйләргә кирәк. Ләкин сөйләүчеләр бүтән төркемнәрдән була. Аның өчен һәр төркемнең яклаучысы бүтән

төркемгә бара, андагы укучылар яклаучыны үзләренең интеллект карталары белән таныштыралар. Яклаучы шушы төркемнең эшен сөйли. Яклаучы сөйләгәндә төркемдәгеләр картинаны карап утыралар, кисәтү ясыйлар, өстәмәләрне әйтәләр. Яклаучы төркем эшенә бәя бирә. Картаны урнаштыра, рәсемне куя.

Өй эше итеп календарьлар таратылды Анда Пластовның "Печән өсте" картинасының кечерәйтелгән репродукциясе һәм сылтамалар язылган. Бу сылтамалар аша Яңа Третьяков галереясына кереп башка рәссамнарның картиналары белән танышырга һәм А.А. Пластовның биографиясе, "Печән өсте" картинасының язылу тарихын укырга тәкъдим ителде.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, заманча инновацион технологияләр кулланып үткәргән дәресләр укучыларда фәнгә кызыксыну уята, фикерләү сәләтләрен үстерә.

*Фәрхетдинова Тәслимә Флеровна,*
*МБББУ "Җәлил икенче урта гомуми белем бирү мәктәбе" нең башлангыч сыйныф укытучысы*

## ***Башлангыч сыйныфларда сөйләм телен үстерү***

Туган тел – рухи байлыгыбыз. Һәркем үз баласын акыллы, булдыклы, тәүфиклы, игелекле итеп күрергә тели. Туган телендә тәрбияләнгән бала гына шундый сыйфатларга ия булып үсә.

Укучыларны әдәби сөйләм теленә өйрәтү кыен. Кече яшьтәге мәктәп балаларының бәйләнешле сөйләмен үстерүгә ирешү максатыннан, башлангыч класслар өчен программадан файдаланып, мин түбәндәге план төзедем:

1.Балаларның сүзлек запасын ачыклау.

2.Укытучы соравына җавапны ачык, кыска һәм төгәл әйтү.

3.Сөйләмнән җөмләне аерып алу.

4.Рәсем буенча җөмләләр төзү.

5.Рәсемнәр сериясе буенча сюжет логикасы сакланган кечкенә хикәя төзү.

6.Укылган җөмләләргә, текстка куелган сорауларга җавап бирү.

7.Төрле күренешләрне телдән сурәтләү.

8.Тәкъдим ителгән яисә балалар үзләре уйлаган тема буенча телдән яисә язма сөйләм төзү.

9.Шигырь, инша, әкиятләр иҗат итү.

Мәктәптәге бер генә дәрес тә, бер генә эш тә сөйләм телен үстерү бурычларын читләп үтми. Балаларның сүз байлыгын системалы рәвештә арттыруга яңа сүзләр өйрәтү нәтиҗәсендә ирешеп була. Таныш булмаган сүзләрне төрле иллюстрацияләргә карап аңлату, уеннар һәм аралашу аша хәтердә калдырырга мөмкин.

Фикерне дөрес итеп әйтеп бирергә өйрәтүнең иң таралган эш формаларының берсе – рәсем буенча сөйләтергә тырышу. Моңа сораулар бирү юлы белән ирешергә мөмкин. Монда укытучының үрнәк сөйләме зур роль уйный. Сөйләгәндә баланың җөмләне грамматик яктан дөрес итеп төзүенә аеруча зур игътибар бирергә кирәк. Сөйләм үстерү эшчәнлеген әйләнә-тирә, табигать күренешләре белән бәйләп, матур әдәбият әсәрләрен уку аша үткәрү уңышлы. Ә. Бикчәнтәева, Б. Рәхмәт, Р. Миңнуллин, Х. Халиков шигырьләре ятлау һәм хәтердә калдыру өчен дә бик уңайлы. Матур рәсемле әкият китаплары, беренчедән, гүзәл зәвык тәрбияләргә ярдәм итсәләр, икенчедән, сөйләм телен үстерүдә алар алыштыргысыз чыганаклар. Шигырь, кыска хикәя, әкиятләрне кабат-кабат уку бик отышлы алым булып тора. Әдәби әсәрләр укыгач, балаларга сораулар бирәм. Һәм аларны шул сорауларга җавап бирергә өйрәтәм. Балаларның монологик сөйләменең үсешенә игътибар итәргә тырышам. Дәресләрдә гадәти күнегүләр белән

берраттән, кроссвордлар, ребуслар чишү дә тел байлыгын арттырырга ярдәм итә. Моннан тыш, төрле мәзәкләрне,кечкенә күләмле әкиятләрне сәхнәләштереп күрсәтү дә укучыларга иректе сөйләмдә сүзләрне урынлы куллана белергә булыша.

Балаларны җөмләдә сүзләрне дөрес куллана белергә, туган телнең матурлыгын тоярга, үз фикереңне ачык һәм дөрес итеп язарга өйрәтүдә иҗади эшләрнең әһәмияте зур.

Беренче класстан ук балаларга бәйләнешле сөйләмгә куелган таләпләрне аңлатам. Алар түбәндәгеләр.

1.Сөйләм эчтәлекле булырга тиеш.

2. Сөйләм логикалы, ягъни акылга ятышлы булырга тиеш.

3. Сөйләм ачык булырга тиеш.

4. Сөйләм саф, чиста булырга тиеш.

5. Сөйләм грамматик яктан төзек, орфографик һәм пунктуацион яктан дөрес булырга тиеш.

6.Сөйләм тел чараларына бай булырга тиеш.

7. Сөйләм тәэсирле булырга тиеш.

Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә дә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.

*Фахразиева Наиля Раисовна,*
*учитель английского языка*
*МБОУ «СОШ с. Чубар-Абдуллово»*

## *Развитие межкультурной коммуникативной компетентности обучающихся*

Происходящие сегодня изменения в общественных отношениях, средствах коммуникации (использовании новых информационных

технологий) требуют повышения коммуникативной компетенции учащихся, изучение английского языка как средства общения.

В современном мире человек все больше сталкивается с необходимостью сотрудничества и общения с представителями других стран. Но люди, живущие на разных концах света, не могут мыслить одинаково и понимать друг друга с полуслова.

Обучение языку неотделимо от знакомства с культурой страны, где говорят на этом языке, с особенностями быта и менталитета их граждан. Но разве возможно изучать культуру другой страны, читая текст, написанный не носителями языка.

Чтобы привлечь учащихся к традициям страны изучаемого языка, я провожу ряд различных уроков, например: за неделю до определенного праздника, я делю класс на две команды. Одна собирает материал, как празднуется этот праздник в Британии, а другая – в России. В каждой команде выбирается капитан, который, собрав всю информацию свое группы, и выступает перед классом. Учащиеся сравнивают традиции празднования того или иного праздника как в Британии так и в России. Ученики прежде ищут песни, рецепты блюд, а затем передают эту информацию другим в классе.

Каждый год мы ставим по 2 театрализованных мини спектакли, где дети с желанием принимают участие. Даже ребенок, который не проявляет активности в изучении языка, принимает участие в этих спектаклях и театрализованных представлениях.

Стараюсь, по возможности проводить разные конкурсы, используя родной язык детей. Конкурс на лучший проект по теме «СМИ в Британии и Татарстане»; «Конвенция по защите прав детей»; «Спорт и здоровый образ в Англии, России» т.д. Ежегодно на недели английского языка стараюсь запланировать мероприятия. В этом году с большим интересом ребята всю неделю посвятили Индии. Выпустили газеты,

подготовили презентации, подготовили информацию о традиционных блюдах индийской кухни. Смотрели видео об национальных костюмах, танцах.

Концепция диалога культур предполагает наличие как минимум двух различных культур в процессе подготовки к реальной межкультурной коммуникации. В самом понятии межкультурной коммуникации заложено равноправное взаимодействие представителей разных общностей с учетом их самобытности и своеобразия, что приводит к необходимости выявления общечеловеческого на основе сравнения изучаемой и собственной культур.

Обучение языкам и культуре в нашей стране сопряжено с рядом трудностей, так как обучаемые не вступают в реальную межкультурную коммуникацию, отсутствует возможность общения с носителем другой культуры. Создаваемые в рамках учебного процесса языковые и культурные ситуации не могут быть приравнены к межкультурным явлениям, так как порождаются носителями одной и той же культуры. В связи с этим трудно согласиться с утверждением С.Г. Тер-Минасовой о том, что каждое иностранное слово - перекресток культур.

Литература:

1. Психология общения: энциклопедический словарь/ под общ. ред. А.А. Бодалева. -М.: Ид-во «Когито-Центр»,

2. Бодалев, А.А. Психология общения / А.А. Бодалев. - М.: Изд-во «Институт практической психологии», Воронеж: НПО «МОДЕК», 1996.

*Халимова Галия Җәмил кызы,*
*Лениногорск шәһәре, 4 урта мәктәбең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Рус мәктәпләрендә татар телен өйрәнү: проблемалар, чишелешләр**

Бүгенге информациягә бай , минут саен меңләгән яңалык булып торган дөньяда яшәү һәм үз-үзеңне югалтмау, адашып калмау бурычы һәрберебез алдында тора торган бурычларның берсе. Кемдер бу бурычны үти ала, ә кем өчендер ул үти алмаслык авыр . Шуның өчен хэзерге заман мәктәбе каршына дөньякүләм интегралда яши һәм үсә алырлык яңа шәхес формалаштыру таләбе куела. Бүген тормышта укыту һәм тәрбиянең яңа төрләрен эзләү, аларны куллану кирәклеге бик нык сизелә. Бүгенге укытучылар, класс җитәкчеләре мәктәптән үз-үзенә ышанган, мөстәкыйль эш итә торган, көндәшлеккә сәләтле, дөрес аралашу серләрен белүче, рухи дөньясы бай, иң матур кешелек сыйфатларына ия булган чыгарылыш сыйныф укучысы әзерләп чыгарырга тиеш .Күргәнебезчә, таләпләр бик зур. Бу максатны тормышка ашыру өчен, укытучыларның һөнәри осталыгын арттыру, аларны яңа педагогик технологияләр, метод һәм алымнар белән эшләргә өйрәтү, шуның нигезендә укучыларга белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү өстендә эшләргә кирәк . Бүгенге көндә югары уку йортларында хәзерге заман укучысы белән кулга-кул тотышып эшли белүче , балаларны телнең серле дөньясына алып керүче яшь кадрлар әзерләүдә ниндидер тотрыксызлык сизелә.

Барыбыз да беләбез: 2017 нче ел ана теле могаллимәсе каршына зур проблемалар куйды. Укыту планыннан алып ташланган дәресләр саны күп кенә укытучыларны тәртәдән чыгарып, гаҗиз калдырды. Нишләргә ? дигән сорау бөтен республика татар телчеләре алдына куелды. Ни генә булмасын укыту систмасында тәҗрибәсе булган укытучылар, үзләренең

юлыннан читкә тайпылмады. Без бу проблемага җавапны үзебездән эзләдек. Чыннан да, күп кенә галимнәр дәреслекләрне дә бетереп ташлады, УМК ларны да үзгәртергә тәкъдим ясады. Минем уйлавымча, дәреслекләр, аларның эчтәлеге, материалның бирелешендә хата юк. Ә менә укытучыларның шул дәреслек белән дөрес куллана белмәвендә бит безнең бәла. Дәреслектә язылган һәр күнегүне эшләп бетерергә дигән максатны минем бер җирдә дә укыганым юк. Ә менә коммуникатив , аралашу юлларын, ысулларын кулланып укыту турында һәрдаим сөйләнә.

Нәкъ шушы дәресләрнең ролен , әһәмиятен югалтмыйсы иде бит. Безнең ата-аналарыбыз татар теленә ышанычны бөтенләй бетермәде бит. Бүгенге көндә шәһәребез һәм районыбыз күләмендә 64 % ата-аналар һәм укучылар татар телен өйрәнүне ана теле дәрәҗәсендә сайлый. Димәк, кызыксынуны югалтмас өчен, безгә җиң сызганып эшләргә кирәк. Укучыларның татар теле өйрәнү серләренә төшендерү класстан тыш чараларда да башкарыла . Һәркем өчен туган ягы бик кадерле . Туган туфрак кешене иманлы итүдә зур роль уйный. Безнең як даһи шәхесләргә бик бай як. Шуның өчен дә тел өйрәтүнең бер чарасы итеп “ Әдәб мирас” музее эшчәнлеген алабыз . Шул кысаларда өлкән класс укучылары белән берлектә “Утыз Имәни мирасын укыту – тәрбия процессында куллану” дигән проектны тормышка ашыру өстендә эшлибез

Шуны истә тотып, өлкән класс укучыларына Утыз Имәни иҗатын өйрәтү буенча электив курслар үткәрү өчен программа төзелде.

Программа укучыларның сәләтләрен ачыкларга, төрле традицион булмаган дәрес формалары аша дөрес сөйли, аралаша, фикерләрен аңлаешлы, эзлекле итеп әйтә белүнең киләчәк тормышта кирәк булуына инандыру өчен укытучыга зур ярдәмлек булып тора.

Программада төрле эш формалары бирелде: конференцияләр, диспутлар, әдәби кичәләр, очрашулар, лекцияләр. Күләмле, кирәкле мәгълүматлар сыйдырган дисклар, төрле презентацияләр куллану курсның эчтәлеген тагын да баета. Бу проект чикләрендә 4 мәктәптә татар әдәбияты ,татар теле, дәресләрендә Утыз Имәни иҗатын өйрәнү конкретлаштырылды. Класс сәгатьләрен үткәргәндә аның әсәрләрен куллану буенча методик рекомендацияләр әзерләнде.

*Хөсәенова Фәйрүзә Василовна,*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләендә уен технологиясе**

Бүгенге көндә заман татар теле һәм әдәбияты укытучылары алдына зур бурычлар куя: үз предметыңа карата бала күңелендә кызыксындыру уяту, уку сыйфатын күтәрү, заманга яраклашкан, конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү. Укытучының педагогик осталыгының торган саен әһәмияте арта бара. Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану- яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уен технологиясен куллану – укучыларда текст, дәреслек белән эшләү, йөгерек, аңлы уку күнекмәләрен булдыру, яңа материалны ныгыту өчен гаять кирәкле алымнарның берсе. Уен – гаҗәеп киң төшенчә. Бала дөньяга аваз салгач, әйләнә-тирәдәгеләрне әзме-күпме таный башлагач, аңарда уйныйсы килү теләге туа. Шуңа күрә дә ата-аналар сабыйлары өчен төрле төстәге, төрле авазлар чыгаручы уенчыклар ала башлыйлар. Шул уенчыкларга карап елмайган бала әйләнә-тирәдәгеләрдә зур канәгатьләнү хисләре

тудыра. Нигә соң әле шушы уенны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә кулланмаска? Бу уеннар балаларга ныклы белем бирергә, тотрыклы күнекмәләр булдырырга, мөстәкыйль рәвештә танып-белү эшчәнлеге белән кызыксынуларын уятырга ярдәм итәләр. Уен технологиясе кулланылган дәрестә укучы актив катнаша, һәр яңаны нәтиҗәле итеп танып белә.

Уен – мәҗбүрилектән котылу юлы, кеше уйнаган вакытта үзен иркле тота, иҗат итә башлый, бары тик яшәешнең табигый эчке законнарына гына буйсына башлый. Дәресләрдә уен алымнарын, эш төрләрен төрлечә сайларга мөмкин, ләкин һәр уен ныклап уйланган, һәрьяклап эшкәртелгән булырга тиеш. Уенны нәтиҗәле үткәрү өчен, укучыларны кызыксындырырлык проблемалы сораулар куя белүнең дә әһәмияте зур.

Уеннарны гадәттә берничә төркемгә бүлеп йөртәләр:

1) әле өйрәнелмәгән татар лексикасын үзләштерергә ярдәм итүче уеннар;

2) өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итүче уеннар;

3) грамматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирүче уеннар;

4) грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итүче уеннар.

Формалары буенча алар телдән һәм язма уеннарга, өстәл һәм хәрәкәтле уеннарга бүленәләр.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча укучы темага үзе килергә тиеш, шушы максатны күз алдында тотып, укучыларга дәрес башында ребус яки кроссворд тәкъдим ителә. Укучы шуны чишеп, дәрестә өйрәнеләчәк теманы китереп чыгара.

Сүз төркемнәрен өйрәнүне йомгаклаганда, укучылар белән “Бәхетле очрак” уенын үткәрү бик уңышлы. Укучыларга телдән җавап бирү өчен төрле биремнәр тәкъдим ителә. Уен биш өлештән тора. Беренче өлештә

сүз төркемнәре буенча бер минут эчендә сораулар бирелә, икенче этапта сурәт-сораулар, өченче этапта – командаларның бер-берсенә сораулары һ.б.

“Лексика” бүлеген үткәндә, “Кем күбрәк?” уенын үткәрәм. Укучылар игътибарына бер сүз бирелә, алар шул сүздәге хәрефләрне файдаланып, мөмкин кадәр күбрәк сүзләр төзеп язарга тиешләр.

Уйлау, фикерләне ныгыту максатыннан, “Җөмлә төзе” уены үткәрергә мөмкин. Укытучы бер сүз әйтә, ә укучылар бер-бер артлы шул сүз белән сүзтезмәләр, яки гади җөмләләр төзиләр.

Фразеологик әйтелмәләрне үткәндә, “Дөресен сайлагыз” уенын үткәрергә була. Тотрыклы сүзтезмәләрнең мәгънәләренә туры килгән карточкаларны табу укучыларда әлеге авыр үзләштерелә торган теманы истә калдырырга ярдәм итә.

Әдәбият дәресләрендә әсәр буенча укучыларның үзләреннән тест сорауларын төзетү дә әсәрнең эчтәлеген җентекләп белергә булыша. Мәкальләрне дәвам итү уены да укучылар өчен кызыклы. Язучыларның иҗатлары буенча КВН, викторина, “Иң йомшак буын” уеннары укучыларда матур әдәбиятка карата мәхәббәт тәрбияли.

Укучыларны дәрес вакытында ял иттереп алу максатында үткәрелгән физкультминутларны да тема белән бәйләп, уен рәвешендә үткәрүне үз тәҗрибәмә керттем. “Очты-очты”, “Бас - утыр”, “Әйе-юк димәскә, ак-карага тимәскә” уеннарын балалар яратып уйныйлар.

Гомумән, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә баланың логик фикерләвен, иҗади көчен үстереп, төрле тәрбия бирүдә һәм баланы тормышка әзерләүдә уеннарның әһәмияте зур.

Әдәбият исемлеге:

1. Н.Гыймадиева “Дәрестә һәм дәрестән соң”- Казан, “Яңалиф” китап нәшрият йорты, 2004 нче ел.

2. “Татар телен һәм әдәбиятын заман таләпләре кушканча укытабыз”- Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015 ел.

*Ханнанова Венера Данифовна,*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе”нең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

**Туган тел дәресләрендә инновацион технологияләр кулану**

**(“Кәрзин ысулы”)**

ФГОС таләпләре буенча белем бирүнең төп максаты- укучыларга белемнәр, күнекмәләр бирү генә түгел, ә аның үзен мөстәкыйль рәвештә белем алырга һәм бу белемнәрне тормышта иҗади кулланырга өйрәтү. Бу максатны тормышка ашыру өчен безгә инновацион технологияләр булыша.

Бу технологияләрнең өстенлекле яклары күп:

- материал югары күрсәтмәле дәрәҗәдә булуы белән отышлы;
- укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар;
- контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары;
- дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Туган тел дәресләрендә “Дөрес җаваплар кәрзине» уенын ” ныгыту, кабатлау дәресләрендә еш кулланам. Укучылар төркемнәрдә эшлиләр. Һәр төркем 1 сорау ала, аңа 3-4 җавап тәкъдим ителә, шуның дөрес булганын гына сайлап алып кәрзингә салалар. Мәсәлән 1 төркемгә сорау: Сыйфат нәрсәне белдерә?

- Предметны белдерә;
- Предметның билгесен белдерә;
- Предметның эшен белдерә

Шулай итеп, уен формасында оештырылган дәресләр шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудырып кына калмый, баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Укучы дәрестә өйрәнелә торган материалның асылына төшенеп, тулысынча анализлый, нәтиҗәләр чыгара. Бу технологиянең нигезендә стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, катлаулы проблемаларның яңа чишелешен табу һәм иҗади эшләү ята. Бу акыл эшчәнлегенең гадидән катлаулыга таба үсешен тәэмин итәргә ярдәм итә.

Әдәбият:

1.Ә.Н.Хуҗиәхмәтов. Педагогик технологияләр: уку ярдәмлеге.- Казан: Мәгариф, 2008;

2. Бутенко А.В., Ходос Е.А. Критическое мышление: метод, теория и практика. Учебно-методическое пособие, – Москва, 2002;

3. Нигматуллин А.З. Технологические – методологические аспекты проблемного и развивающего обучения (На материале дидактики и школьного преподавания литературы народов РФ). - Уфа-Елабуга, 1999;

*Хәмидуллина Алсу Хусяиновна,*
*МБББУ “Җәлил икенче урта*
*гомуми белем бирү мәктәбе" нең*
*башлангыч сыйныфлар укытучысы*

## Рус телле балаларга татар теле укытудан эш тәҗрибәсе

Мин – башлангыч сыйныф укытучысы… Максатым – рус балаларын татарча аралашырга өйрәтү, һәр укучыга иҗади мөмкинлекләрен табарга ярдәм итү, үзенең көченә ышандыру, барлык эшләрне булдыра алырдай шәхес икәнен күрсәтү. Ә бу максатларга ничек ирешергә соң? Кайчагында – фәнни һәм методик әдәбиятта, хезмәттәшләремнең тәҗрибәләрендә, ә кайчагында үзем укыткан укучыларның күзләрендә...

Укучы телне гамәли яктан үзләштерергә, дөрес тәрҗемә итәргә, ишетеп аңларга,төрле темаларга сөйләшү оештырырга тиеш.

Шул максаттан чыгып, мин Р.З.Хәйдәрова методикасына нигезләнеп эшлим.

Укыту методлары-укытучы белән укучының белемнәрне үзләштерү өлкәсендә (яңа материалны аңлату, белем һәм күнекмәләрне ныгыту, системага салу, гомумиләштереп кабатлау һәм башка өлешләрендә) бергәләп эшләү юллары ул:

-укучылар ныклы белем һәм күнекмәләр алсын өчен, шартлар тудыру;

-татар телендә иркен аралаша, сөйләшә алуга ирешү;

-эзлекле фикер йөртергә сәләтле укучыны төрле яклап үстерү;

-телгә өйрәнүне татар халкының тарихы, сәнгате, мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән тыгыз бәйләүгә юнәлеш бирү;

-телгә өйрәнүне әхлакый-эстетик тәрбия бирү белән берлектә алып баруга юл күрсәтү.

Фикерне әйтү өчен тел байлыгы,сүз байлыгы кирәк. Яңа сүзләр өйрәнгәндә, аларның синонимнарына зур игътибар бирәм. Дәресләрдә мин төсле рәсемнәр кулланам. Алардан файдаланып, балаларның иҗади фикерләре байый, мөстәкыйльлекләре арта.

Заман куйган таләпләрне искә алып, укучыларга төрле белем һәм тәрбия бирү өчен иҗади эшләргә тырышам.Төрле темаларга, мәсәлән, “ Якын дустым”, “Минем яраткан шөгылем” , “Минем ял көнем” кечкенә иншалар язганда, укучыларга уйларга, хыялланырга, фикер йөртергә шартлар туа.Иҗади сәләтләрен арттыру өчен, бирелгән рифмаларга таянып, укучылар дәрестә кечкенә шигырьләр язып карыйлар.

Рус балаларын татарча саф, дөрес сөйләшергә өйрәтер өчен, кыска монологлар, диалоглар, төрле хикәяләр төзү файдалы. Мәсәлән: “Мин әкиятче”, “Президентка хат”, “Мин телевизион тапшыруны алып баручы”, “Мин яшәгән урам”, “Әбиләрдә кунакта”.

"Чылбырлы" уеннар үткәргәндә, балалар тема буенча өйрәнгән сүзләрне искә алалар. Бу уен җаваплылык, игътибарлылык таләп итә.

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту уңай нәтиҗә бирә. Укучылар телне аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, логик фикерләргә өйрәнә. Төркемләп эшләгәндә, көчлерәк укучылар авыррак үзләштерүчеләргә ярдәм итә. Кайберләре сүзләргә синонимнар таба, сорауларга җавап бирә, план төзи; башкалары тәрҗемә итә, җөмләләр төзи, текстны сөйли. Кечкенә төркемнәрдә иң кыюсыз, оялчан, материалны начар белгән бала да көчлерәк укучының җавабын дәвам итә ала. Үз эшеннән канәгать булып, тагын да күбрәк белү, өйрәнү теләге уяна.

Бирелгән тема буенча монологик сөйләм төзегәндә, мәсәлән: "Кышкы каникулда", "Ел фасыллары", "Минем гаиләм"- балаларның сүзлек байлыгын, мөстәкыйль эшли белүен истә тотам, сүзлекләрдән һәм башка чыганаклардан файдаланырга өйрәтәм.

Мәктәптә баланы югары әхлаклы, тормышка әзерлекле итеп укыту-тәрбияләүдә мин халык педагогикасы алымнарын киң кулланам. Халык педагогикасында борынгы заманнардан ук халык акылы, аның зирәк фикерләре, киңәшләре, үгет-нәсихәтләре тупланган һәм аларны һич тә югалтырга ярамый. Балаларны халыкның үзенә генә хас булган тарихи үсешен, аның психологиясен чагылдырган белем һәм тәрбия бирү ысуллары, буыннан-буынга күчеп үсәргә, камилләшергә тиеш.

Биремнәрдә мин еш кына мәшһүр мәгърифәтче Р. Фәхреддинның халык педагогикасына нигезләнеп язылган "Нәсихәт"еннән өзекләр файдаланам.

Балаларны халык гореф-гадәтләре нигезендә тәрбияләүне өстен күрәм. "Сабантуй", "Нәүрүз", "Карга боткасы", "Әбиемнең сандыгы" дигән бәйрәмнәр шушы максаттан уздырылды.

Әлбәттә, замана күзлегеннән чыгып караганда һөнәрем җиңел түгел, ләкин эшеңне яратсаң, һәр иртәдә ашкынып мәктәпкә килсәң, балаларның зур ышаныч белән сиңа төбәлгән карашларын күрсәң, барлык арулар юкка чыга, һәм эшеңнең кирәклеген аңлап, хезмәтеңнән канәгатьләнү, шатлык хисе чолгап ала.

*Хамидуллина Сомбел Нафисовна,*
*“Азнакай шәһәре 7 нче урта*
*гомуми белем бирү мәктәбе”нең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

**“Кошлар тумый канатсыз, кеше тумый талантсыз”**

“Кошлар тумый канатсыз,кеше тумый талантсыз”, - ди татар халык мәкале. Чыннан да, һәр кешедә нинди дә булса бер шөгыльгә сәләт булмый калмый. Тик аны ачыклый, таба белергә һәм үстерергә генә кирәк.

Шуның өчен без, башлангыч сыйныф укытучылары, дәрес вакытында да, дәрестән тыш вакытта да укучыларның сәләтләрен ачарга, үстерергә ярдәм итәргә тырышабыз. Телләрне үзләштерү өчен иң кулай чор, билгеле булганча, ул балалык вакыты, мәктәптә уку еллары. Шуңа күрә мәктәпләрдә башка милләт балаларына да дәүләт телләренең берсе – татар телен өйрәтү өчен шартлар тудырып, аларны кызыксындырып, дәресләрне генә түгел, дәрестән тыш чараларны да тиешле дәрәҗәдә үткәрү зарур.

Мәгариф системасына кертелгән яңа федераль дәүләт стандартлары дәрестән тыш эшчәнлекне 5 юнәлештә алып баруны таләп итә һәм һәр яктан камил,мөстәкыйль ,иҗади шәхес тәрбияләү максатын куя. Шул юнәлешләрнең берсе булган - эстетик тәрбия бирү юнәлешендә кече яшьтәге мәктәп балалары өчен “Мизгел”иҗат берләшмәсен ачтык.

Берләшмәбезнең беренче максаты – баладагы мавыгуларны, омтылышларны үстерү, аңа сәләтен табуда һәм камилләшүдә булышу. Икенче максат – балада эчке табигый көчләрне үстерү.

Белем һәм тәрбия бирү бер-берсеннән аерылгысыз. Дәресләрдә алган белемнәрне мәктәптәге түгәрәкләрдә камилләштерү, тулыландыру һәм ныгыту бүген көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

Баланың мәктәптән нинди шәхес булып чыгуында, киләчәктә нинди һөнәр сайлавында укыту -тәрбия эшенең роле бик зур.

Түгәрәкнең эш формасы күп төрле: театр эшчәнлеге һәм культурасы, сәхнә теле һәм актерлык осталыгы,театральләштерелгән уеннар, декорацияләр әзерләү һәм китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, укылган китап буенча киносценарийлар төзү, шигырь укучылар бәйгеләре оештыру, әдәби - музыкаль монтаж әзерләү, музейларга бару, җирле матбугат белән танышу, рецензия язарга өйрәнү, һ.б. бик күп төрле эш алымнары кулланыла.. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра.

Балалар уку-танып белү эшчәнлегенең башлангыч ысулларына ия, аларны камилләштерергә һәм баетырга омтылалар. Һәрберсендә сәнгатьле уку, сәхнәдә матур итеп чыгыш ясау теләге бар. Коллектив белән уртак тел табып анда күмәк яши беләләр. Балалар үзләре алдына куелган бурычны яхшы аңлыйлар.Театр уеннары укучыларның фикерләү сәләтен һәм иҗади фантазиясен үстерүгә уңай йогынты ясый. Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыра, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арта, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туа. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә. Укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә юнәлтелгән эзлекле эш үзенең

нәтиҗәләрен дә бирә. “МИЗГЕЛ” иҗат берләшмәсе оешканнан бирле зур күрсәткечләргә ирешеп килә. Соңгы 3 елда гына алган күрсәткечләр: республикакүләм милли балалар“Сәйәр”театр фестивалендә 1 урын, республикакүләм милли балалар“Сәхнә көзгесе” театр фестивалендә 59 команда арасында 1; “Иделкәем” балалар театр коллективы республикакүләм смотрында 1 урын, республика күләмендә уздырыла торган сәламәтлек театрлары бәйгесендә 1,2 урыннар.Безнең Азнакай районында сәләтле балалар өчен төрле номинацияләрдә “Чулпан” премиясе тапшырыла. “МИЗГЕЛ” иҗат берләшмәсе дә бу конкурстан читтә калмый. 2010,2015 нче елларда лауреат исеменә лаек булды. Алдагы елларда “Акыллы ябалак” бүләгенә ия булсак, соңгы елларда үзебезнең район бизәге булган Актүбә уенчыгын алдык. Һәр уку елы азагында түгәрәкнең эшенә нәтиҗә ясала. Уку елы дәвамында башлангыч сыйныф укучылары алдында , балалар бакчасында чыгышлар ясала .Түгәрәк эшендә катнашкан укучылар мәктәп, район һәм республика күләмендәге бәйгеләрдә югары күрсәткечләргә иреште.

Театр – милләт язмышының һич тутыкмас көзгесе ул. Бик күп еллар дәвамында татар милләтенең рухын, милли үзенчәлеген, телен, әхлагын саклап һәм үстереп, безне бербөтен халык итеп тотучы театр һичшиксез, олы ихтирамга, чиксез мәхәббәткә лаек. Һәр кешенең җанында театрга карата булган мәхәббәт яши. Шуңа күрә мәктәбебезнең йөзе булып яшәп килгән театрыбыз киләчәктә дә чәчәк атар, дип өметләнеп калабыз.

Балалар иҗаты- бетмәс-төкенмәс хәзинә, байлык. Тик аны вакытында ача белергә генә кирәк. Аларга ялкынлы илһам, сүнмәс дәрт, якты ышаныч өстәп торыйк! Иҗат чишмәләребез саекмасын!

*Хафзетдинова Эльвира Равиловна,*
*Бакалы районы Мостафа урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы*

**Яңа технологияләр җирлегендә**
**укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү**

Нәни кеше дөньяга килә! Ул шундый саф, эчкерсез! Шушы саф җанлы, эчкерсез баланы дөньяга әзерләү, тормышта югалып калмаска өйрәтү, үз кыйбласын табарга ярдәм итү, илебез терәге булырлык шәхес тәрбияләү - һәр укытучының изге бурычы. «Яңа технологияләр җирлегендә укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү» инновацион пректы өстендә эшләргә алындым. Темамны актуаль дип саныйм, чөнки илебезгә иҗади, үзаллы фикерле, талантлы балалар сорала. Үз халкыңның тарихын хөрмәт иткән, традицияләрен, гореф-гадәтләрен белгән, иҗади конкурентлыкка ия булган шәхес тәрбияләү-төп бурычым дип саныйм. Проект нигезендә укучыларны иҗади яктан үстереп, эзләнүләр аша бүгенге мәктәп куйган таләпләргә җавап бирә дип уйлыйм.

«Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта үз урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен шартлар тудырырга кирәк»,- дип язган Л.Н. Толстой.

Шушы фикерне алга куеп, эшемнең максаты итеп түбәндәгене билгеләдем:

Максат: Һәрьяклап гармоник үсешкә ирешкән, тирәнтен фикерли алучы һәм иҗади сәләткә ия шәхес тәрбияләү.

Педагогик бурычлар:

1. Укучыларга дәүләт стандартларына туры килерлек белемнәр бирү; эзләнергә, гадәти булмаган шартларда фикер йөртергә өйрәтү, иҗади сәләтләрен үстерү.

2.Югары әхлакый сыйфатларга, интерактив, коммуникатив мөмкинлекләргә ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.

3. Конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү.

Шушы максат һәм бурычлар, этаплар аша нәрсәгә ирешергә телим соң? Проект бүгенге чынбарлык таләпләренә җавап бирә. Укучыларның күпьяклы иҗади сәләтләрен ачу,үстерү, туган җиренә җаны-тәне белән береккән югары рухлы һәм милләтебезнең йөзен билгеләүче әхлакый кыйммәтле,тормышта һәрнәрсәгә үз фикере булган,үз карашын яклый алган, туган илен,халкын, телен сөйгән шәхесләр тәрбияләү.

Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү юлларын 3 этапка бүлдем:

1нче этапта диагностика ярдәмендә укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклыйм.

2нче төп этапта шушы нәтиҗәләрне күз уңында тотып эшлим.

Проектның соңгы 3 нче этабында, шушы система буенча эшне дәвам итеп, көтелгән нәтиҗәләр тулысынча акланыр дип уйлыйм.

Ә рухи байлыкка ничек бәя куярга, ничек диагностика үткәрергә соң? Үз-үзләрен тотышыннан, бер-берләренә мөнәсәбәтеннән, иҗади эшләреннән чыгып бәялибез. Ләкин иң дөрес бәяне аларга тормыш үзе куячак.

Минем инануымча, иҗади сәләтне үстерү педагогик проекты буенча эшләү укучыларда максатчанлык, хезмәт сөючәнлек һәм башка әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә,туган җирне ярату, аның кешеләренә карата хөрмәт хисе, матурлыкны күрә белү сыйфатлары формалашуга, укучыларның рухи мәдәниятен баетуга булышлык итә. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә.

*Шәңгәрәева Нәзифә Наиловна,*
*МБББУ “Җәлил икенче урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең башлангыч сыйныф укытучысы*

**Телләрне укыту: заманча һәм инновацион технологияләр**

«Технология» (сәнгать, осталык дигәнне белдерә).

Инновацион технологияләрне укыту процессында файдалану-белем бирү сыйфатын күтәрүдә бик нәтиҗәле чара ул. Чөнки алар укуга кызыксыну тудыра, уку материалын тирәнрәк үзләштерү теләге булдыра, укучыларның иҗади сәләтен үстерү мөмкинлеген бирә.

Теләп башкарылган эш кенә истә кала, баланың сәләтен, аңын үстерә. Әгәр материалны үзләштерү авыр, бертөрле икән, укучының күңеле суына, телне өйрәнергә булган теләге бөтенләй сүнергә дә мөмкин.

Рус мәктәбендә ана теле буларак татар теле укытуның төп бурычлары:

1. Татар телен өйрәнүгә кызыксынуны көчәйтү,үз теленә, милләтенә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт тәрбияләү.

2. Татар теленең барлык тармаклары аша эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.

3. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.

4.Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү.Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.

5. Туган тел аша өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.

6. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.

Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычны да онытмаска кирәк.

Күптән түгел генә Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты белән берлектә татар тел укытучыларына ярдәмгә бала.рф сайты булдырылды. Мәгариф сыйфатын үстерү максатын алга куеп эшләнгән «БАЛА» дип аталучы мультимедиалы интерактив китапханә татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнүгә юнәлтелгән.

Мин үземнең эш тәҗрибәмдә түбәндәге заманча технологоияләргә мөрәҗәгать итәм:

1) уен технологиясе;

2) компьютер технологияләре;

3) электрон дәреслекләр һәм ярдәмлекләр.

Минем дәрес “Җөмләнең баш кисәкләре”.

Максат: Укучыларга җөмләнең баш кисәкләре турында гомуми теоретик белем бирү; практик куллана белү күнекмәләре бирү; экологик тәрбия бирү.

Бурычлар:

– өйрәнелгәннәрне билгеле бер системага салу, алган белемнәрне ныгыту;

– сөйләм телен һәм сәнгатьле сөйләмне камилләштерү;

- үз-үзеңә бәя куярга өйрәтүне дәвам итү,

– проблеманы күмәк хәл итәргә омтылыш теләген үстерү, дуслык, бердәмлек, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.

Предметара бәйләнеш: Рус теле, рәсем сәнгате, музыка, әйләнә-тирә дөнья.

Дәрестә кулланылган методлар: традицион метод һәм алымнары белән беррәттән яңа педагогик технологияләр (мәгълүмати-коммуникатив технология).

Планлаштырылган нәтиҗәләр.

Шәхескә кагылышлы: -Татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.

*Ширеева Алсу Сәгыйтовна,*
*“Азнакай шәһәре 4 нче лицее” нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уку грамоталылыгын формалаштыру**

Федераль дәүләт белем бирү стандартында белем бирүнең төп максаты билгеләнгән, ул – бала шәхесен үстерү. Әлеге бурычны уңышлы хәл итү шартларының берсе – универсаль уку гамәлләрен формалаштыру. Ә УУГ исемлегендә үзәк урынны нәкъ менә уку грамоталылыгы алып тора.

PISA халыкара тикшеренүләре күрсәткәнчә, Россия укучылары үз яшьтәшләреннән уку күнекмәләренең формалашуы дәрәҗәсендә шактый артта кала. Материалны укыганнан соң, укучы нәтиҗәләр ясарга һәм бирелгән мәгълүмат белән файдалана белергә тиеш. Моның өчен текстны аңларга, сүзнең ни хакта барганына төшенергә кирәк. Россия балалары нәкъ соңгысы белән кыенлык кичерә дә икән. Шуңа күрә, бүгенге көндә мәктәп укучысында уку грамоталылыгын булдыру мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора да инде. Бу күнекмәне формалаштыру һәм үстерү эше даими алып барылырга тиеш, чөнки укый белү күнекмәсе укучының гомуми әзерлек дәрәҗәсен билгели һәм укучыга үзлектән яңа белем алырга да мөмкинлек бирә. Уку күнекмәсенең тиешле дәрәҗәдә булмавы укучыга мәктәптә генә түгел, югары уку йортында да тирән белем алуга киртә булырга мөмкин. Мәктәпнең бу өлкәдәге бурычы – укыган текстны дөрес аңларга һәм

анализларга сәләтле, фикер йөртә белүче, үз фикерләрен эзлекле һәм аңлаешлы итеп башкаларга җиткерә алучы заманча шәхес әзерләү.

Укучыларның уку грамоталылыгын тәэмин итү өчен, татар теле һәм әдәбияты укытучысы нәрсә эшли ала соң? Бу юнәлештә инновацион педагогик технологияләрне куллану зур роль уйный. Критик фикерләү технологиясе, тикшеренү методы, проект эшчәнлеге, продуктив уку технологияләре, укытуның төркем һәм коллектив формаларын куллану яхшы нәтиҗәләргә китерә. Әлеге технологияләр кысаларында кулланыла торган алымнар укучылар ихтыяҗын канәгатьләндерә, телдән һәм язма формада фикерләрне кыска итеп бәян итүгә сәләтләрен үстерә, фикерләү эшчәнлеген активлаштыра һәм, гомумән, төрле компетенцияләр формалаштыруга ярдәм итә.

Уку грамоталылыгын формалаштыру өчен үзем куллана торган алымнарның кайберләрен карап үтәргә тәкъдим итәм. «Сез ышанасызмы» алымы дәреснең традицион булмаган башлангычы булырга һәм шул ук вакытта текст белән уйлап эш итәргә, мәгълүматны тәнкыйть белән кабул итеп, аның төгәллеге һәм кыйммәте турында нәтиҗәләр ясарга ярдәм итүче алым буларак кулланыла. Укучыларга дәреслектә бирелгән кагыйдәне укыганчы раслаулар тәкъдим ителә, текст белән танышканнан соң аларга кабат әйләнеп кайтып, нәтиҗәләр турында фикер алышу оештырыла.

«Буш урынлы хат» алымы исә текстагы кирәкле мәгълүматны аерып ала белү, төп һәм ярдәмчел мәгълүматны билгели белү күнекмәсен формалаштырырга ярдәм итә.

«Түгәрәк хат» алымы текстта бирелгән мәгълүмат турында уйланырга, автор позициясе белән килешү яки килешмәүне белдерергә, элек укылганнар белән дә, үзләренең тормыш тәҗрибәләре белән дә чагыштырырга өйрәтә.

«Хатаны тап» – игътибарны активлаштыручы универсаль алым. Ул мәгълүматны анализлау, стандарт булмаган ситуациядә белемнәрне куллану һәм бәяли белүне формалаштыра.

«Түгәрәк буенча уку» алымы уку барышында текстны аңлау процессы белән идарә итү максаты белән кулланыла. Текст абзацлап укыла, бер укучы укый, башкалар аңа, текстны аңлап уку дәрәҗәсен тикшерү максаты белән, сораулар бирә. Шунысы мөһим: китап бер экземплярда гына. Текстның эчтәлеген аңлау, шәхси мөнәсәбәтне ачыклау өчен, «Тукталышлар белән уку», «Аңлатмалы уку», «Текст белән диалог төзү» алымнарын куллану да яхшы нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә.

Алда китерелгән алымнарны дәресләрдә куллану укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыруга зур этәргеч бирә һәм укыту-тәрбия процессының сыйфатын күтәрүгә дә ярдәм итә.

*Шаһиева Рузилә Әхмәтзакировна ,*
*“Азнакай шәһәре гимназиясе” нең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

## Яңгырның ял көне

Максат: Яңгырның тәүге үзенчәлекләрен Л. Лерон, М. Җәлил әсәрләре аша күрсәтү.

ТБУУГ: анализлау, чагыштыру, классификацияләү, гомумиләштерү.

РУУГ: үз эшеңә бәя бирә белү.

КУУГ: тормыш тәҗрибәсен куллану.

ТБУУГ: анализлау, чагыштыру, классификацияләү, гомумиләштерү.

РУУГ: үз эшеңә бәя бирә белү.

КУУГ: тормыш тәҗрибәсен куллану.

Бурычлар: Л. Леронның «Яңгырның ял көне», М. Җәлилнең «Яңгыр» әсәрләрендә яңгырның үзенчәлекләрен төрлечә чагылдыру алымнарын

табып, аңлата белергә өйрәтү. Шигырьдә җанландыру кебек гади әдәби алымны таба белү.

Материал. “Китмә әле, бераз тор”, Йолдызның “Салават күпере”, М. Әлимбаевнең “Салават күпере”, Л. Леронның «Яңгырның ял көне», М. Җәлилнең “Яңгыр” әсәрләре.

Җиһазлау. презентация, дәреслек 1 нче кисәк, дәреслек- хрестоматия 3 нче кисәк, тест материалы, аудиоязма.

Дәрес барышы

Дәресне оештыру. Мотивация.

Кем җырлар, моңнар ярата,

Кемнәр ачык күңелле,

Кем дуслык, туганлык яклы,

Бергә башлыйк дәресне.

— Хәерле сәгатьтә, дуслар! Барыгызны да дәрескә чакырам.

Дәреснең максатын билгеләү. Актуальләштерү

-Укучылар, табышмакны игътибар белән тыңлагыз һәм нәрсә турында сүз баруын әйтегез.

Күктән килде, җиргә иңде. (Яңгыр).

- Балалар, әйтегез әле нәрсә ул яңгыр?

- Рәсемнәргә карагыз эле, монда бертөрле яңгыр сурәтләнгәнме?

- Табигатьтә нинди яңгырлар очрый?

- Сез яңгыр яратасызмы?

Балалар, әйдәгез бергәләп «Яңгыр яу» җырын (Резеда Валеева сүзләре, Илфир Якубов көе) тыңлап узыйк.

- Сезгә җыр ошадамы? Бу җырда нәрсә турында сүз бара?

- Бәлки, сез миңа бүгенге дәрес темасын да әйтергә ярдәм итәрсез.

-Әйе, без бүген дәрестә яңгыр турында әсәрләр белән танышырбыз.

Яңа материалны аңлату.

Л.Лерон турында кыскача мәгълүмат бирү.

Сүзлек өстендә эш.

http://tatarschool.ru/ сайтында 4 дәрескә бирелгән материал белән танышу, биремнәрне үтәү.

Л. Леронның «Яңгырның ял көне» әсәрен уку. Эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү.

- Ничә көн яңгыр ява?

- Дүшәмбе яңгыр ничек ява?...

- Яңгыр кайчан туктый?

Сорауларга җавап бирү:

- Әсәрдә нинди яңгыр турында сүз бара?

- Әсәр героена якшәмбе көн ошыймы? Ни өчен?

- Бөтен нәрсәнең дә ял көне була микән?

- Автор безгә бу шигыре белән нәрсә әйтергә тели?

- Автор ничек итеп яңгырга җан өрә?

- Әдәбиятта җансыз предметны җанлы итеп курсәтү - җанландыру алымы дип атала.

Белемнәрне беренчел ныгыту.

М. Җәлил турында кыскача мәгълүмат бирү.

М. Җәлилнең «Яңгыр» әсәрен уку.

- Бу әсәрдә нинди яңгыр турында сүз бара?

- Яңгыр ничек ява?

- Сезнең мондый яңгыр күргәнегез бармы?

- Бу ике әсәрдә яңгыр бертөрлеме?

- Ни өчен Л. Лерон әсәрендәге яңгыр ял ала, ә М. Җәлил әсәрендәге яңгырны кыр көлеп каршы ала?

- Бу әсәрдә җанландыру алымы безгә очрадымы?

- Син яңгыр яратасыңмы? Ни өчен?

Мөстәкыйль эш.

Сорауларга кыскача җавап бир

1. Ләбиб Леронның «Яңгырның ял көне» шигырендә әсәр герое ни өчен арый?

2. Ләбиб Леронның «Яңгырның ял көне» шигырендә атнаның кайсы көнендә чиләкләп яңгыр ява?

3. Муса Җәлилнең «Яңгыр» шигырендә яңгырның тәмамлануы кайсы дүртьюллыгында күрсәтелгән:

4. Муса Җәлилнең «Яңгыр » шигырендә яңгыр ни өчен ашыгып китә?

5. Бу ике шигырьдә нинди әдәби алым кулланылды?

Мөстәкыйль эшне тикшерү.

Презентация буенча эшне тикшерү, билге кую.

Җаваплар

- Яңгыр ява да ява
- Пәнҗешәмбе
- Өченче
- Сугарырга күрше кырларны
- Җанландыру

Дәрескә йомгак. Рефлексия.

— Дәрестә өйрәнгәннәр сиңа кызыклы булдымы?

— Тагынниләр белергә телисең?

— Үз җавапларыңнан канәгать калдыңмы?

Өй эше. 1) Әсәрләрне дөрес интонация белән укырга өйрәнергә; 2) Яңгыр турында табышмак, сынамыш, ырымнар, эндәшләр табарга, рәсем ясарга; 3) «Яңгырның ял көне ничек уза?» темасына иҗади эш (рәсем яки инша).

**Содержание:**

**Рахманов А.М.** Гимназия шартларында укучыларда милли үзаң тәрбияләү ....................................................................................................................3
**Шамсиева Г.М.** Азнакай муниципаль районында милли мәгариф........................................................................................................... 6
**Ахмадишина Л.И.** Туган телне укытуда заманча һәм инновацион технологияләр.........................................................................................................10
**Ахметзянова З.Ю.** Туган тел дәресләрендә укыту материалын визуальләштерү алымнарын куллану..........................................................................12
**Ахметханова С.Ф.** Как научиться запоминать 100 иностранных слов за 1 час?..................................................................................................................................14
**Бахтиева С.А**. Фрагмент урока "Театр сәнгате", "Theatre"............................16
**Габдрахманова А.М.** Место и роль родного языка в обучении иностранному языку................................................................................................19
**Гараева З.М.** Особенности применения интерактивных методов в преподавании татарского языка в русскоязычных группах..........................21
**Гилязова А.А.** Использование арт-технологий на уроках английского языка........................................................................................................................23
**Гумарова Р.М.** Особенности фонетики татарского языка при изучении английского языка в общеобразовательных учреждениях...........................26
**Давлетова В.А., Мирсияпова Г.Г**. Интегрированное внеурочное занятие "Звуки и буквы английского и татарскогоязыков".........................................27
**Ибрагимова Ч.Р.** Мастер-класс "Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә Блум шакмагын куллану"....................................................................................31
**Мухутдинова Р.Ф.** Татар теле һәм әдәбиятын укытуда инновацион технологияләр. Тестлар төзүдә GOOGLE формалар куллану............................34
**Марданшина Л.М.** Инновационные подходы к повышению педагогической компетенции педагогов в сфере формирования интеллектуальных и творческих способностей детей......................................37
**Мияссарова Л.К.** Туган тел дәресләрендә Plickers ресурсын куллану.....40
**Назмутдинова Р.Р.** Формирование межкультурной коммуникативной компетенции учащихся аудиовизуальными средствами...............................42
**Насипова Г.Ш.** Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә критик (тәнкыйди) фикерләү алымнарын куллану..........................................................45
**Рахманова Ф.И.** Башлангыч сыйныфларда "Фишбоун" алымын куллану"......................................................................................................................................50
**Садриева Ф.А.** Заманча технологияләрне куллану туган (татар) телне укыту процессын тагын да нәтиҗәлерәк итә.........................................................54
**Тинбакова Р.В.** Башлангыч сыйныф укучыларына татар телен өйрәткәндә образлы күзаллау алымнары (эш тәҗрибәсеннән)................57
**Фазлыева Г.Н**. *А*.А.Пластовның "Печән өсте" картинасына тасвирлама бирү...............................................................................................................................*59*
**Фархутдинова Т.Ф.** Башлангыч сыйныфларда сөйләм телен үстерү.....61

**Фахразиева Н.Р.** Развитие межкультурной коммуникативной компетентности обучающихся.............................................................................**63**
**Халимова Г.З.** Рус мәктәпләрендә татар телен өйрәнү: проблемалар, чишелешләр..............................................................................................................**66**
**Хусаинова Ф.В.** Татар теле һәм әдәбияты дәресләендә уен технологиясе..............................................................................................................**68**
**Ханнанова В.Д.** Туган тел дәресләрендә инновацион технологияләр кулану(“Кәрзин ысулы”).............................................................................................**71**
**Хамидуллина А.Х.** Рус телле балаларга татар теле укытудан эш тәҗрибәсе..............................................................................................................**72**
**Хамидуллина С.Н.** “Кошлар тумый канатсыз, кеше тумый талантсыз”.............................................................................................................. **75**
**Хафзетдинова Э.Р.** Яңа технологияләр җирлегендә укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.............................................................................................**78**
**Шангараева Н.Н.** Телләрне укыту: заманча һәм инновацион технологияләр..............................................................................................................**80**
**Ширеева А.С.** Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уку грамоталылыгын формалаштыру......................................................................**82**
**Шагиева Р.А.** Яңгырның ял көне......................................................................**84**